

ШЕШӘДӘ – АГУ

Ялган аракы эчеп агуланучылар саны арта

> 5

БАГУЧЫГА БАРМА:

күрәзәчеләр коронавирустан «дәвалый» башлаган

> 16

РАЯЗ ФАСЫЙХОВ:

«Халыкка ярарга тырышып иҗат итмәдем»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 168 (28750) | Җомга | 19 ноябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

«Татар-информ»

ЕГЕТ БУЛЫЙК, ИРЛӘР!

ХАЛЫКАРА ИРЛӘР КӨНЕ УҢАЕННАН УЙЛАНУ

Гаиләсен туендыручы, сөйгәненә – калкан, терәк, баласына – үрнәк, ил-көндә дәрәҗәле, кеше янында абруйлы. Ир-ат затын көчле иткән әлеге сыйфатлар, кызганыч, хәзер элеккечә актуаль түгел. «Чын ирләр калмады инде» дигән кызгану катыш көлемсерәп әйтелгән сүзләрне ешрак ишетергә туры килә. Монда хатын-кыз да гаепле, ди кайберәүләр. 19 ноябрь – Халыкара ирләр көне уңаеннан без ир-ат абруе турында фикерләшергә булдык.

> 6

Ишетми калмагыз

Яңа елга кадәр – ярминкә

11 сентябрьдән бирле Татарстанда барлыгы 9 авыл хуҗалыгы ярминкәсе үткәрелгән. Анда чама белән 1 миллиард сумлык продукция сатылган. Бу хакта Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итә. Фермерлар шәһәр халкына, аерым алганда, 4703,3 тонна бәрәңге, 697,1 тонна кәбестә, 308,6 тонна кишер, 296,7 тонна кызыл чөгендер һәм 2140 тонна башлы суган саткан. Ярминкәдә азык-төлек бәясе кибетләрдәгегә караганда арзанрак. Бу арадашчыларны читләтеп сатуга, шулай ук фермерларга бушлай сәүдә урыннары бирелүгә бәйле. Ярминкәләр Яңа елга кадәр уздырылачак. Билгеле булганча, сәүдә урыннары Казанда 15 мәйданчыкта, Чаллыда, Түбән Камада һәм Яшел Үзәндә оештырыла.

Сүз уңаеннан, «Известия» хәбәр иткәнчә, Россиядә бәрәңгене күпләп сатып алу бәясе узган ел белән чагыштырганда 71,4 процентка арткан. Авыл хуҗалыгы, Сәнәгать һәм сәүдә министрлыклары, һава торышы аркасында бәрәңге уңышы аз булганлыктан, аны БДБ илләреннән сатып алырга ниятли.

10 көн ял итәчәкбез

Яңа ел каникулы, узган елдагыча, 10 көнгә сузылачак. 31 декабрьдән киләсе елның 9 гыйнварына кадәр ял итәчәкбез. Моңа кадәр Премьер-министр Михаил Мишустинның быел 31 декабрьнең ял көне итеп билгеләнүе турында карарны имзалавын искә төшерик. Карар хөкүмәт сайтына урнаштырылган. Анда 2, 3 гыйнвар ялларының (шимбә һәм якшәмбе) 5 ноябрьгә һәм 31 декабрьгә (икесе дә – җомга) күчерелүе искәртелә.

Бозга чыккан өчен штраф

Лаеш районында коткаручылар Рыбнадзор хезмәткәрләре белән быел тәүге рейд уздырган. Рождествено бистәсе янында Мишә елгасына юка гына боз өстенә 20ләп балыкчы җыелган. Тикшерүчеләрне күрүгә, алар төрлесе төрле якка качкан. Шулай да дүртесен тотканнар. Бозның калынлыгы үлчәнгәч, балыкчыларның җаваплылыктан кача алмавы ачыкланган. Боз катламының калынлыгы 5 сантиметр чамасы гына, җитмәсә ныгымаган, көпшәк. Хәзер закон бозучыларга 2шәр мең сум күләмендә штраф түләргә туры киләчәк. Мондый рейдлар якын арада тагын үткәреләчәк, аларның максаты – халыкны әле катып өлгермәгән бозга чыгудан кисәтү.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Районда 50 ятим һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган бала бар. Шуларның 16сы – тулы, 34е – социаль ятимнәр. Районның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе Наталья Шибаева әйтүенчә, профилактик эш алып барылуга карамастан, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү һәм чикләү очраклары арта. Быел ун айда 45 ата-ана 73 балага карата үз хокукыннан мәхрүм ителгән. Биш баладан тугач ук баш тартканнар, аларны башка гаиләләр алган. Быел 30 баланы – туганнары, тагын 4есен чит гаиләләр тәрбиягә алган. 3 бала уллыкка алынган, тагын 2се үз гаиләсенә кайтарылган. 11 сабый вакытлыча Татарстанның балалар йортларына урнаштырылган.
(e-nkama.ru)

Алабуга

Район авылларында Яңа ел бәйрәме уңаеннан йөздән артык чара узачак. Бу хакта җитәкчеләр киңәшмәсендә җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгы Евгений Кольцов сөйләде. Авыл халкы арасында «Кардан ясалган иң матур сын» һәм «Иң матур бизәлгән йорт» конкурслары игълан ителде, аларның нәтиҗәләре буенча җиңүчеләрне җирлек башлыгы бүләкли. Җирлек башлыклары «Алабуга муниципаль районы составына керүче авыл торак пунктларында иң яхшы Яңа ел бизәлеше» конкурсында катнаша. 1 нче урынга – 25000, 2 нче урынга – 15000, 3 нче урынга 10000 сум бирелә.
(«Алабуга нуры»)

Апас

Районда аз керемле гаиләдә тәрбияләнүче балаларга хоккей кирәк-яраклары бүләк иттеләр. «Максатыбыз – хоккейны популярлаштыру, моның өчен тиешле шартлар булдыру. Аз керемле гаиләләрнең балаларына хоккей киемнәре бүләк итү – аларга шөгыльләнү өчен мөмкинлек тудыру», – диде тантанада Татарстанның Хоккей федерациясе башкарма директоры Кирилл Голубев. Район башлыгы Айрат Җиһаншин районда хоккейга карата зур игътибар бирелүен, шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр булдырылуын әйтте. Апас Боз сараенда 192 бала хоккей белән шөгыльләнә. 100 бала фигуралы шуу түгәрәгенә йөри.
(«Апас-информ»)

Актаныш

Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең туган авылы Әнәккә быел 6500 турист килгән. Бирелә аның әтисе Шәрип Шәймиевнең музей-йорты урнашкан. Узган ел исә авылда Хезмәт Герое Минтимер Шәймиевкә бюст һәм «Бабайда кунакта» ял паркы ачылды. «Узган ел 3500 кеше кунак булган иде. Димәк, Әнәк туристик авыл булып танылып килә. Безнең авылда Чаллы рәссамнарының картиналар галереясы ачылу зур вакыйга булды. Сәнгать әсәрләре белән танышу туристларның сәяхәтен тагын да тулыландырып җибәрер», – ди Пучы авыл җирлеге башлыгы Нияз Нуретдинов.
(«Актаныш-информ»)

QR-КОД: ЧИРАТСЫЗ ҺӘМ ТЕРКӘЛҮСЕЗ ГЕНӘ

Бер сәгать урынына бер минут көтәсе. Махсус теркәлү узасы юк, кулда паспорт булу да җитә. Һәркем өчен дә бик әһәмиятле саналган QR-кодны Татарстанның күпфункцияле үзәкләре тизрәк алу мөмкинлеген булдырган. Бу инде чиратларны да киметер, эшне дә җиңеләйтер, дип өметләнә хезмәткәрләр.

mfc16.tatarstan.ru

Татарстанда барлык күпфункцияле үзәкләр дә ялларсыз кабул итә, шәхси сәхифәне раслату (ЕСИА) һәм QR-код бастырып чыгару өчен иртәнге 8.00 сәгатьтән кичке 17.00 сәгатькә кадәр хезмәт күрсәтү каралган. Якшәмбе көннәрендә мөрәҗәгать итүчеләрне хезмәткәрләр 9.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр кабул итәчәк.

Күпфункцияле үзәкләр хәзер Россия Цифрлаштыру министрлыгы булдырган махсус хезмәттән файдалана. Коронавируска каршы вакцина ясаткан һәм соңгы ярты елда вирус йоктырып, чирләп алган кешеләрнең белешмәләре шунда урнашкан. Хезмәт QR-кодлы белешмәләрне тизрәк бастырып чыгарырга ярдәм итә. Моңа кадәр күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белешмә сорап мөрәҗәгать итүчеләргә аны «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша әзерләп бирә иде. Тоткарлыклар да булмады түгел. Хәзер инде эш тизрәк барыр, мөгаен. Бигрәк тә пенсия яшендәге әби-бабайлар, заманча кәрәзле телефоны булмаганнар өчен аеруча кирәкле үзгәреш инде бу. Сүз уңаеннан, әлеге мөмкинлектән бер көн эчендә 5400 кеше файдаланып өлгергән.

– Кешеләр порталда «шәхси кабинет» булдырырга омтыла, әмма аны ясаган вакытта бутала, ялгыша, берничә «сәхифә» ясый иде, – ди Татарстанның күпфункцияле үзәкләре директоры Ленара Мозаффарова. – Әгәр дә «Дәүләт хезмәтләре» системасында кешенең икенче сәхифәсе барлыкка килә икән, шәхси кабинетка керү булмаячак. Аны «бит»нең иясе үзе генә артык мәгълүматтан чистарта да алмаячак. Бу республикада яшәүче бик күпләрнең хатасы иде. Алар барысын да тәртипкә китерү өчен безгә мөрәҗәгать итте, без аларның шәхси сәхифәләрен чистартканнан соң гына, QR-код пәйда була иде.

Хәзер ничек булачак соң? QR-код алу өчен күпфункцияле үзәккә килгәндә кулда шәхесне раслаучы документ (паспорт, СНИЛС, ОМС) булу шарт. Ә менә «Дәүләт хезмәтләре» порталында теркәлмәскә дә мөмкин. Моннан тыш, туганың, күршең, дустың өчен дә QR-кодны барып алырга була. Моның өчен икенче заттан ышанычнамә кәгазе генә таләп ителә. Аны-сын нотариуста рәсмиләштерергә кирәкми. «Ышанычнамә язганда исем, фамилия, әтисенең исеме һәм белешмәне барып алучы кешенең шушы ук мәгълүматлары күрсәтелә. Әйтик, студентлар төркеменең старостасы бөтен төркемдәшләре өчен белешмә алырга мөмкин. Белешмәне вакцина ясатканнарга да, чир кичергән кешеләргә дә чыгартып бирәбез. Белешмәдә исем, фамилия, әтиегезнең исеме һәм паспорт мәгълүматларыннан тыш, бернинди медицина мәгълүматлары юк. Моңа кадәр күпфункцияле үзәккә килеп, белешмәне кәгазьгә бастырырга өлгергән кешеләргә, яңасын ясатырга дип, янәдән үзәккә киләсе түгел», – дип аңлатты Ленара Мозаффарова.

Халыкны сабырсызланмаска өнди күпфункцияле үзәк белгечләре. Тиз була дип ышандырсалар да, системаның киреләнгән чагына да туры килүләре бар.

– Белешмәне чыгартып булмаса яисә аны системада тиз генә таба алмасалар, мөрәҗәгать итүчеләр офис хезмәткәрләре белән бәхәсләшмәсеннәр иде. Бу бездән генә тормый, медицина оешмаларының тизлеге дә йогынты ясый, – ди Ленара Мозаффарова.

Сан

11 октябрьдән **16** ноябрьгә кадәр, «Дәүләт хезмәтләре» порталында шәхси сәхифәне (ЕСИА) раслату өчен, республиканың күпфункцияле үзәкләренә **246** мең мөрәҗәгать кергән. **9** ноябрьда бер тәүлеккә **11** мең кеше кабул иткәннәр. Бу – шушы вакыт аралыгындагы иң зур күрсәткеч.

Яңа кагыйдәләр

22 НОЯБРЬДӘН ГАМӘЛГӘ КЕРӘЧӘК ЧИКЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ БИЛГЕЛЕ БУЛДЫ

Татарстан Министрлар Кабинеты, коронавирус инфекциясе таралуга каршы тору максатыннан, республиканың җәмәгать транспортында пассажирлар өчен чикләү чаралары кертү турында карар кабул итте. Рәсми документ Министрлар Кабинетының 208 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертә. Алар 22 ноябрьдән башлап гамәлдә булачак.

Шулай итеп, Татарстан халкы нинди үзгәрешләргә әзер булырга тиеш?

• 15 ноябрьдән театр, кинотеатр, цирк, концерт залларына 18 яшьтән өлкәнрәк тамашачылар бары тик QR-код күрсәткән очракта гына керә ала;

• 22 ноябрьдән башлап 18 яшьтән өлкәнрәк кешеләргә җәмәгать транспортында (такси, җиңел машиналардан тыш), метро, шәһәрдәге җир өсте электр транспортында QR-код белән генә йөрү мөмкин;

• 22 ноябрьдән автовокзалларда, автостанцияләрдә шәһәр яны һәм муниципалитетара маршрутларга билет сату QR-код күрсәткән очракта гына башкарыла. Искәрмә булып 18 яшьтән яшьрәк һәм төбәкара пассажирлар тора.

• 22 ноябрьдән 60 яшьтән өлкәнрәкләрнең транспорт карталары эше туктатылачак. Соңгы 6 ай эчендә коронавирус белән рәсми авырган һәм «медотвод»лы кешеләр искәрмә булып тора.

Карар санитар-эпидемиологик вазгыять яхшырганчы театр, кинотеатр, цирк, концерт залларының эше QR-кодлы халык саны 50 процентган да артмаган, 500дән артык кеше тулмаган очракта гына мөмкин булуын күздә тота.

Документта язылганча, «медотвод»лы кешеләргә җәмәгать урыннарында йөрү рөхсәт ителми. Моның өчен бары тик вакцина ясаткан яисә чир белән авырган булу турында белешмә кирәк.

ТӨП МӘСЬӘЛӘ – БЮДЖЕТ

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының егерме җиденче утырышы 25 ноябрьдә үткәрелә. Кичә парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Депутатлар 21 мәсьәлә, шул исәптән 5 федераль һәм 9 республика законы проектын карап тикшерергә ниятли.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, гадәттәгечә, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карауга керешкәнче, соңгы вакытларда республикада булган кайбер мөһим вакыйгаларны билгеләп үтте. Парламент башлыгы октябрь – ноябрь айларында узган Бөтенроссия халык санын алуга аерым тукталды. «Безнең республика җанисәп алуда бик актив катнашты, – дип билгеләп үтте парламент башлыгы. – Аның уңышлы тәгаенләнүендә Дәүләт Советы депутатларының да өлеше бар».

«2022 елга һәм пландагы 2023, 2024 еллар чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проекты, һичшиксез, парламент утырышында караласы төп мәсьәлә булачак. Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина әйтүенчә, беренче укылышта каралганнан соң, закон проектына 533 төзәтмә кертелгән. Кайберләрен авторлар үзләре үк карап тикшерүдән төшереп калдырган, 511е кабул итүгә тәкъдим ителгән.

Шулай ук Татарстан Сайлау кодексына, инвестицион эшчәнлек турында законга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан закон проектлары тикшерeләчәк. Ә инде янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге эшчәнлекне, умартачылыкны үстерүне җайга салучы закон проектлары беренче укылышка әзерләнгән.

Парламент утырышында Дәүләт Советының 2022 елга закон проектлары буенча эшләүнең якынча планы да каралачак.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин утырыштан соң журналистлар сорауларына җавап бирде. Аерым алганда, бюджет турында законны икенче укылышка әзерләү барышында 2022 елга республика бюджеты дефицитының 24 миллиард сумга җиткерелүен ул республика хакимиятенең әле тагын кайбер илкүләм проектларда, дәүләт программаларында катнашырга ниятләве белән бәйләп аңлатты. «Аларда катнашуның шарты булып, төбәк бюджетыннан финанслашу тора, – дип искәртте Фәрит Мөхәммәтшин. – Республикага бу программаларда катнашу отышлы булачак, шуңа бюджетның чыгым өлешен һәм бюджет дефицитын арттырырга карар кылдык».

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Мәскәүдә 2030 елга кадәр Россия төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык тармагын үстерү стратегиясе буенча семинар-киңәшмә узды. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин сүзләренә караганда, стратегия илкүләм проектларны гамәлгә ашыру максатыннан Президент Указында билгеләнгән бурычларны үтәүне күздә тота. «Без 2030 елга һәм пландагы 2035 елга кадәрге чорга төзелеш тармагын үстерү стратегиясен әзерләдек. Аның буенча фикер алышу өчен субъектлар җитәкчеләре катнашында семинар-киңәшмә үткәрдек. Чараның максаты – аралашу, ил күләмендә төзелеш тармагына кагылышлы стратегик юллар табу, тәҗрибә алышу», – дип аңлаткан Марат Хөснуллин.

Стратегиянең төп максатларыннан берсе – кешеләргә торак шартларын яхшырту мөмкинлеге бирү. Моның өчен, Россия вице-премьеры билгеләп үткәнчә, торак-коммуналь хуҗалыкны камилләштерүгә, социаль объектлар төзүгә, гомумән, төбәкләрнең социаль-икътисади үсешенә инвестицияләр кирәк.

Исегезгә төшерәбез: 2030 елга кадәр төзелеш тармагын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү стратегиясендә бу вакытка әчке тулай продукт күләмендә тармак өлешен 5,1 проценттан 5,8 процентка кадәр җиткерү максаты куелган. Шул ук вакытта бер ел эчендә файдалануга тапшырылырга тиешле торак мәйданы 120 миллион кв. метрга (хәзерге вакытта – 86 миллион кв. метр) җиткерелергә тиеш.

***

Мәскәүдә «Сыйфатлы имин юллар» илкүләм проектын гамәлгә ашыру буенча иң яхшы төбәк башлыкларын бүләкләделәр.

Аларга истәлекле бүләкләр һәм дипломнарны РФ Президенты Администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары Сергей Кириенко, РФ Президенты ярдәмчесе һәм РФ Дәүләт Советы секретаре Игорь Левитин, шулай ук РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин тапшырды. Бүләк алучылар арасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та бар.

РИШВӘТЧЕЛЕК КЫЙММӘТКӘ ТӨШӘ

ТАТАРСТАНДА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ АРАСЫНДА КОРРУПЦИОН ҖИНАЯТЬЛӘР САНЫ АРТКАН

Социаль челтәрләр – халык белән элемтәдә тору өчен дә, ришвәтчелек очракларын кисәтү өчен дә менә дигән мәйданчык. Ришвәтчелеккә каршы тору мәсьәләләренә багышланган матбугат очрашуына килгән белгечләр беравыздан әнә шул фикерне кабатлады. Республиканың күп кенә районнары шушы заманча мөмкинлекне күптән эшкә җиккән инде.

pixabay.com

Теләче районы башлыгы Нәҗип Хаҗиповның эш иртәсе социаль челтәрләрне тикшереп чыгудан башлана икән. «Яңа көннең 20 минутын шушы социаль челтәрләрдәге хәбәрләрне өйрәнүдән башлыйм. Араларында турыдан-туры безнең җаваплылыкка караганнары очраса, ул сорауны шундук игътибар үзәгенә алабыз. Хәл итәргә тырышабыз», – ди район башлыгы. Түбән Кама башлыгы Рамил Муллин яңа вазыйфага билгеләнүенең өченче көнендә үк «ВКонтакте», «Фейсбук», «Инстаграм» кебек иң популяр челтәрләрдә шәхси аккаунтын булдырган.

– Алар аша безгә халыктан бик күп сораулар килде. Бу бик уңайлы. Кешенең район башлыгы янына килеп, аның белән күзгә-күз карап сөйләшергә мөмкинлеге, вакыты булмаска мөмкин. Ә монда ул үзен борчыган сорауны язып калдыра ала. Халыктан килгән сорауларга җавап биреп, аларны җаваплы кешеләр адресына юллаганыңны күргәч, алар да синең ачык булуыңны белә. Район башлыгы үзе дә ниндидер кагыйдә бозу очраклары барлыгын, теге яки бу юнәлештә барысының да тиешле дәрәҗәдә эшләнәме-юкмы икәнлеген абайлап бетермәскә мөмкин. Без ачык һәм гадел булырга тиеш. Еш кына күпләр сорауны йомып калдырырга тырыша. Әйтик, теге яки бу эшне башкарырга матди мөмкинлекләр юк икән, аны ничек бар шулай – әлегә акча юк шул дип турыдан-туры җавап бирергә кирәк», – ди район башлыгы.

Барлык җитәкчеләр дә шул фикердә торса ярый да бит. Агымдагы ел башыннан бирле дәүләт хезмәтендәге һәм муниципаль хезмәттәге дүрт кеше, ышанычны югалту сәбәпле, эштән алынган инде. Татарстан Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе баш киңәшчесе Салават Рәхимов әйтүенчә, эшсез калган дүрт дәүләт хезмәткәренең икесе – Чистай һәм Теләче районнарыннан. Алар керемнәре турында мәгълүмат тапшырудан баш тартканнары өчен вазыйфаларыннан азат ителгән. Шундый ук язмышка дучар ителгән Түбән Кама депутаты керемнәре турындагы белешмәдә эшмәкәрлек эшчәнлегеннән алган 300 мең сумлык табышын күрсәтмәгән, йөк машинасын сатуын да яшереп калдырган. Вазыйфасыннан азат ителгән Яшел Үзән районы депутаты депозит счетлардан процент рәвешендә алынган 270 мең сумнан артык табышын яшереп калдырган булган.

Агымдагы елның 9 аенда республиканың җирле үзидарә органнарында ришвәтчелеккә каршы законнар өлкәсендә 254 закон бозу очрагы ачыкланган. Бу, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 1,5 тапкыр күбрәк.

– Быел дәүләт һәм муниципалитет хезмәткәрләре арасында 280нән артык тикшерү үткәрелде. Нәтиҗәдә 254 закон бозу очрагы ачыкланды, 242 кеше җавапка тартылды. Моннан бер ел элек мин үткәрелгән барлык тикшерүләрнең 85–88 процентының кешеләрне җавапка тарту белән тәмамлануы турында сөйләгән идем. Быел исә аларның 95 проценты билгеле бер нәтиҗәләр китерә дип әйтергә мөмкин, – диде Салават Рәхимов журналистлар белән очрашуда.

Ни өчен авыл җирлеге башлыкларын ришвәтчелектә ешрак гаеплиләр? Матбугат очрашуына җыелган белгечләр шушы сорауга да ачыклык кертергә тырышты. Авыл җирендә күпләр – бер-берсенең туганы, бу күренешнең төп сәбәбе әнә шунда, ди белгечләр. «Ни кызганыч, авыл җирлекләрендә еш кына кар түгү, төзекләндерү буенча килешүләр төзегәндә, мәнфәгатьләр каршылыгы күзәтелә. Кагыйдә буларак, монда авыл җирлеге башлыгының да бик күп туганнары яши. Шуңа күрә урамнарны кардан чистарту өчен килешү дә еш кына башлыкның берәр туганы белән төзелгән була», – дип ачыклык кертте «Татарстан Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясенең юридик идарәсе башлыгы урынбасары Сергей Столяров.

Матбугат очрашуында белгечләр ришвәтчелеккә каршы актив эшчәнлек алып барган районнарны да атады. Бу исемлеккә Казан шәһәре, Мамадыш, Кайбыч, Ютазы районнары кергән. Арча, Актаныш, Әлки, Алексеевск, Әтнә, Югары Ослан, Кама Тамагы, Нурлат, Мөслим, Тукай һәм Чирмешән районнары исә бу юнәлештә – артта калучылар рәтендә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Әйтеп кенә бактым

Үрдәк кыйссасы

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бик озакка сузылды бу кыйсса. Арчаның Урта Курса авылы тавыгы утырып чыгарган кыр үрдәге бәбкәләре турында моннан ике ел чамасы элек яза башлаган идем, әмма язар өчен сәбәп һаман табыла тора. Печән чабучы егет чалгысы белән ялгыш бераз гына койрыгын кискәч, куркып очып киткән һәм шул куркудан оясына кире кайтмаган кыр үрдәгенең тугыз йомыркасыннан тугыз бәбкә чыгып, барысы да матур булып үсеп җитте.

«Арча хәбәрләре» газетасында эшләүче каләмдәшем Ильяс Фәттахов үрдәкләр тормышындагы һәр яңалыкны миңа хәбәр итеп торды. Үрдәкләрнең «анасы», Урта Курсаның ак тавыгы үлеп дә аннан иштеттем.

Узган ел без үрдәкләр җылы якларга очып китәр дип көткән идек, матур итеп озатырга да әзерләндек, әмма ерак юлга кузгалырга исәпләре юк иде. Шуннан, «Ак Барс – Агро» ширкәте җитәкчесе Шәйдулла Сәлахов үз биләмәсендә яшәгән бәбкәләрне кышлату әмәлен кереште, ат фермасында ике бүлмәле «фатир» эшләтте. Бәбкәләр шунда рәхәтләнеп кыш чыктылар. Иртә язда әниләре аларны күлгә алып төште һәм бәбкәләрнең мөстәкыйль тормышы башланды. Күл ярларында оя кордылар, бәбкәләр чыгардылар. Тавык дәү әнигә әйләнде. «Урыны оҗмахта булсын!» – дип әйтмибез инде, кош-корт өчен оҗмахы-тәмугы юктыр, ә менә авыл кешеләре ак тавыкны һаман сагынып искә ала әле.

Яхшы, хуш, дип әйтте ди берәү. Шәйдулла Сәлахов та, кыр үрдәкләре язмышында әһәмиятле роль уйнаган Ильяс һәм, әлбәттә, мин дә, кыр үрдәкләре быел җылы якларга китми калмас дип, «морально и физически» аларны озатуга әзерләнә башладык. Ильяс әле аларны балдаклар киертеп озату турында да хыялланды, кош балдакларын кайда ясауларын да белешеп куйган иде бугай. Әмма үрдәкләр үзләрен бик сәер тотканнар. Көз якынлашкан саен алар турында сүзләр куера торды.

Кыр үрдәкләре ерак юлга чыгар алдыннан ай буе күп ашарга тиеш икән, гәүдә авырлыклары, юл озынлыгына карап, 20–25 процентка кадәр артырга тиеш, ди. Шәйдулла моны белгән, әлбәттә, көн саен күлгә килеп аларга ипи ашатмас иде.

Барлык җан ияләре дә нәкъ кеше кебек, ахрысы, яхшыга тиз ияләшәләр. Күптән түгел Ильяс шалтыратты. «Карале, теге үрдәк бәбкәләре күлне ташлап чыкканнар да, кыр казлары кебек тезелешеп, кире кышкы фатирларына кайтканнар бит, Шәйдулла Имамович аптыраштa», – диде. Иң кызыгы, аларның балалары бер-ике көн узуга шулай ук күлдән чыкканнар да, ат фермасы өстендә әйләнгәннәр-әйләнгәннәр дә әтиәниләре белән сабуллашып, үз ишләренә кушылып, җылы якларга очып киткәннәр, ди. Адәм акыллары бар икән бу үрдәкләрдә, валлаһи.

Безгә моңсу булып калды. Барасы җирләренә исән-сау барып җитәрләр микән? Кошлар буенча белгечкә әйләнгән Ильяс Фәттахов үзенчә тынычландырмакчы була. Үрдәкләр, башка кайбер күчмә кошлардан аермалы буларак, бер-берсен ташламыйлар икән. Сәфәр вакытында берәрсе авырып китсә, төркемнәре белән җиргә төшеп, хәстәрен күрә башлыйлар, ди. Бердәмлек, ярдәмләшеп яшәү аларга геннар буенча килә, ахрысы, нәсел саклар өчен, диюем.

Бердәм булу, бергә булу турында без дә күп сөйләшәбез. Җырлар, шигырьләр чыгарабыз. Хәтта мәзәкләр дә сөйләп йөрибез. Әнә берәү хатыны белән аерылышканда: «Бергә булыйк, бердәм булыйк», – дип әйткән ди, имеш. Бу мәзәктә ачы хакыйкать тә бар: «бердәм» дию еш кына, шулай кирәк, дип әйтелгән сүзгә әйләнеп кала. Һәм авыр хәлгә төшкән кеше турында әчтән генә: «Шул кирәк аңа, ник кадалып китми шунда», – дип уйлаучылар да юк түгел.

Дөрес булса, кошлар бертуктамый сигезәр-унар сәгать оча ала, шуңа күрә сәфәр алдыннан авырлык җыя да. Алар, хәтта, һавада да ашый ала, юлда очраган төрле чебен-черки, бөҗәкләрне, Ильяс әйтмешли, «на ходу» йота икән. «Салкын һавада бөҗәкләр очамыни?» – дип карыйм. Ильяс: «Җылы климатка кергәч ашый алар», – ди.

Балалары кайтуын эти-әниләре дә көтәр. Без дә көтәбез. Шунысы кызык: алар кайтышка Сеҗе авылы янындагы күл киек кошлар белән тулган булырга мөмкин. Безнекеләр шулар арасыннан үз эти-әниләрен табар микән?

Исән булсак, аларны каршы алырбыз һәм кошлар тормышыннан гаҗәеп вакыйгаларга янә тап булырбыз һәм, димәк, үрдәк кыйссасының да дәвамы булыр.

СИНДӘ НИК ЭШ ЮК СОҢ, АВЫЛ?

Танылган бер татар журналисты күптән түгел генә «Фейсбук»та «Ни өчен авылларда эш урыны булдырылмый?» дигән мәсьәләне күтәреп чыкты. Фикерләре дөрес аның. Чынлап та, бүген бит Казан тирәсе районнарыннан иртә таңнан халык Казанга эшкә агыла.

Таң атар-атмастан, йокылы күзеңне ачып, 100–150 километрлы юлга чыгып китү бер дә рәхәт нәрсә түгел бит. Автор тагын бер мәсьәләне дөрес күтәрә: кешесез авылларда социаль объектлар төзү өчен байтак акча тотыла. Димәк, авылга акча бүленми түгел, тиешле юнәлештә генә бүленми. Мантыйк болай формалаша: башта эш урыннары булдырып, кешеләрне, бигрәк тә яшьләрне авылда яшәтеп калдырасың, аннан, кеше саны арта башлагач, социаль объектларны төзү яисә яңарту проблемасын хәл итсәң дә ярый. Социаль объектлар белән җитештерү цехларын бергә үстерсәң, тагын да отышлырак булыр төсле. Теориядә болар барысы да шулай һәм дөрес, әмма тормыш тәҗрибәсе бераз башкачарак нәтиҗәләр күрсәтә.

Иң беренче, «Авылда эш урыннарын кем булдырырга тиеш?» дигән сорау кабыргасы белән килеп баса. Дәүләтме? Әйе, безнең беркатлы фикерләвебез хөкүмәт агайдан инвестицияләр көтә. Бюджеттан акча бүлеп, сөт эшкәртү заводы, ит эшкәртү цехы, кондитер әйберләре җитештерү предприятиеләре ачып кую бик катлаулы эш булмаска тиеш кебек бит инде ул. Әмма ул цехларның һәм заводларның берсе дә эшләп китә алмаячак. Дәүләт предприятиесе – потенциал банкрот ул. Аның башында котылгысыз рәвештә инициативасыз чиновниклар утырачак һәм аларның бар игъдади сәләте хөкүмәт биргән акчаны ничек итеп булса да үз файдасына тотып бетерүгә сарыф ителәчәк. Үз-үзен акламаган һәм бөлгән предприятиене хөкүмәт субсидиясе белән күпме асрап була? Мең предприятиегә бер эшмәкәрлек куәте булган идарәче табып булыр да бәлки, әмма ул гына гомуми вәзгыятьне үзгәртә алмаячак. Бар ул безнең Татарстанда яхшы җитәкче кулы астында уңышлы эшләп килгән колхозлар. Әмма килешик: күп түгел. Аларда җитештерүчәнлек, яңа технологияләр, хезмәт хаклары да чагыштырмача ярыйсы гына. Шулар үрнәгендә башка авылларда да элекке колхозларны тергезеп кенә җибәрәсе кебек, әмма барып чыкмый. Административ ысул белән уңышлы эшли торган предприятие булдыру – күпчелек очракта буш хыял ул.

Димәк, әйдәгез бергәләп нәтиҗә ясыйбыз: авылда эш урыннары булсын өчен, инициативалы хосусый эшмәкәрләр, заманча әйтсәк, инвесторлар кирәк. Юк, теге югарыдан билгеләп куелган инвестор турында сүз бармый. Үз теләге белән авылга килеп, эш урыннары булдырырга һәм табыш алырга атлыгып торган шәхесләрнең пәйда булуын көтәргә туры килә. Алар тусын һәм үсеп җитсен өчен, авылда җитештерү мәйданы ачучыларга өстенлекләр бирергә кирәк, әлбәттә. Сүз азыктөлек җитештерү хакында гына бармый, югары технологияле продуктлар тудыручы эш урыннары да ясап булырга тиештер бит инде. Кытайда бар андый авыллар: продукцияне бөтен дөньяга саталар һәм ярыйсы гына яшиләр дә. Совет чорында бездә дә бар иде авылларда сәнәгать предприятиеләре: азык-төлек комбинатлары, «промкомбинат» дип аталган вак-төяк товар җитештерүче цехлар, ательелар… 1992 ел килеп җитү белән алар бик тиз аякларын сузды. Бездән 7 генә километр ераклыкта Яңа Кенәр яшелчә киптерү заводы 2010 елгы корылыкка кадәр тырмаша-тартыша яшәде дә, чимал – бәрәңге булмау сәбәпле, ишекләрен япты.

Хәер, бер алар гынамы, зур-зур трактор заводлары, авиация заводлары, автомобиль заводлары шәһәрләрдә хәрабәгә әйләнде. Илдә сәнәгать товарлары җитештерү икътисади яктан файдасыз була башлады. Әйе, аларны дөрес булмаган салым сәясәте дә харап итте, приватизацияне «прихватизация»гә әйләндерү дә тамырларына балта чапты, әмма тагын бер нәрсә юкка чыгарды совет чоры сәнәгатен: заводлар эш урыны кирәк булганга күрә генә тотылалар иде. Технологик яктан артта калганга күрә, алар көндәшлеккә сәләтсез булып чыкты. Артталыкның сәбәбе – дәүләт предприятиесе булуда. Авылларда эш урыннары булдыру идеясен байрак итеп күтәреп, хөкүмәт акчасына җитештерү мәйданнары корып куйсак, без тагын шул тырмага басачакбыз: сыйфатсыз товар җитештерүчеләр тудырачакбыз һәм алар тиз бөләчәкләр.

Хосусый инвесторның үз теләге белән авылга килеп тамыр җибәрүе безне коткарачакмы? Әйтик, өстенлекләр тудырсак, ферма төзегән өчен бүлеп биргән ке-

Илдар Мөхәммәтҗанов

бек кайтарып бирелми торган акча бирсәк… Менә монда да барысы да ал да гөл булмаячак әле. Әйдәгез, тормыштан бер мисал карыйбыз. Яндексның элекке хезмәткәре Алексей Конышев дигән бер егет, моннан җиде-сигез ел элек «программачылар авылы» төзим дип, бөтен Россиягә шаулады. Шаулап кына калмады, авылда 17 гектар җир сатып алып, төзеп тә куйды ул аны. Бераздан аның янына айтишниклар килеп төпләнә башлады, җәй көне балаларны программалаштыруга өйрәтә торган мәктәп тә барлыкка килде, конференцияләр үткәрелә торган мәйдан да пәйда булды, авыл (бистә) ут-су, интернет белән тәэмин ителде. Болар өчен креатив инвестор тагын 11 миллион сум үз акчасын тотты, диделәр. Менә бит авылда эш урынары булдыруның идеаль үрнәге. Әмма хәзерге көндә анда эшләр бик үк шәптән түгел, диләр. Айтишниклар инвестор белән тирән конфликтта. Хуҗа авылда эшлим дип килгән егетләрнең өйләреннән интернетны өздергән, суны бикләгән, хәтта буага бару юлына шлагбаум куйган. Хосусый инвесторның да комсызлык һәм нәфес дигән нәрсәләре эшне кирегә өстери башлаган. Шулай булгач, авылда эш урыннары булдыру дигән идея – шәп һәм дөрес идея ул, әмма чынбарлыкта аны тормышка ашыру бик кыен.

Әле төп проблеманы атамадым. Әйтик, гади авыл егете һәм кызына (аерым сәләтләргә ия булмаган дип әйтик инде) шәһәргә китмичә, авылда эшли торган мәйдан булдырсак (сыер саву яки җирдә эшләү түгел), итне һәм сөтне кем җитештерә? Яңа эш урыны гөрләп китсен өчен, анда яхшы эш шартлары һәм әйбәт үк түләү булырга тиеш. Шулай булмаса, кешеләр тагын шәһәргә кыяклый башлаячак. Теге урыннар буш торачак. Ә инде түләүле һәм комфортлы эш урыны булдырсак, беркем дә, таңнан торып, фермага эшкә бармаячак. Шул яңа урынга омтылачак барысы да. Менә монда инде ниндидер яңа предприятие корып куйганчы, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче өстен шартларга куярга туры киләчәк: хезмәт хакы шәһәрдәгедән югары, эш урыны һәм шартлары комфортлы. Менә соңгысына хәзерге технологияләр мөмкинлек бирә инде. Эш ул технологик эш урыннары булдыру өчен кирәкле акчага гына килеп терәлә. Аек акыл белән караганда, азык-төлек продуктларын җитештерү һәрвакытта да рентабельле булырга тиеш, чөнки аларны һәркем кулана. Ихтыяҗ зур. Әмма хәзерге финанс һәм икътисад системасында без кирәксен күрәбез.

Иртән рульгә утырып, авылдан шәһәргә юнәлүчеләр арасында тәҗрибәле агрономнар, тракторчылар, слесарьлар, тагын әллә кемнәр күп. Авылда бик кирәкле кешеләр алар барысы да. Әмма эш урыны бар, түләү юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә шәһәргә үз белгечлекләренә туры килми торган эшләр белән шөгыльләнергә юнәлә алар. Тагын бер кызык нәрсә бар бит әле: шәһәрдә песи дәвалаган ветеринар авылда сыер дәвалаган коллегасыннан берничә тапкыр күбрәк ала. Тракторчы да шулай ук. Диванда мырлап ятучы песи кадәр дә акча китерә алмаган сыер белән изалануга караганда, шәһәрдәге эшне үз күрә икән кеше, аңа ни дип әйтәсең инде?!

Хәзер шәһәрдән авылга кайту тенденциясе дә көчәеп бара. Шәһәр тирәсе авылларында йортлар яңгырдан соң гөмбә калыккан кебек калка. Монысы үзе яңа проблемалар тудыра. Ләкин бу инде – бөтенләй икенче тема.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Теманың дәвамы 7 нче биттә >

ШЕШӘДӘ – АГУ

Соңгы 40 елда Татарстанда токсикология тарихында метанол белән күпләп агулануның бу – беренче очрагы. Шушы көннәрдә республиканы гына түгел, бөтен илне шаулаткан вакыйга турында белгечләр әнә шулай ди. Даны еракларга таралган әлеге очрак ялган хәмер белән сату итүчеләргә сабак бирерме? Әллә алар тагын да мәкерлерәк һәм хәйләкәррәк юллар эзли башлармы? Белгечләр белән шул хакта сөйләштек.

Агулану

Билгеле булганча, Казан янындагы Салмачы бистәсендә бәйрәм иткән 13 егет һәм кыз, ялган аракы белән агуланып, хастаханәгә эләкте. Зыян күрүчеләрнең икесе генә – Казаннан. Калганнары – Башкортстаннан килгән студентлар. Әлегә кадәр өч кыз реанимациядә дәвалана. Табибларга беренчеләрдән булып мөрәҗәгать иткән 19 яшьлек кыз бөтенләй аңында түгел. Хастаханәгә килгәндә ул авырлык белән сөйләшүеннән, күңеле болганудан, кулын күзән җыерудан зарланган. Кан анализлары барлык яшьләрнең дә метанол белән агулануларын күрсәткән.

Тикшерү вакытында 18–22 яшьлек егет һәм кызларның 5 литрлы савытка салынган сыекчаны шушы бистәдәге бер кешедән сатып алулары билгеле була. Моңа кадәр дә шушы ук кешедән исерткеч эчемлекләр сатып алуларын әйтәләр. Соңрак, тикшерү барышында, метанол белән агуланган яшьләрнең хәмер урынына суыкта катмый торган сыекча эчүләре ачыклана. Россия Тикшерү комитетының Татарстандагы идарәсе хәбәрләре буенча, биш литрлы шешәне каршеринг автомобиле багажнигында алып киләләр. Багажникта шундый ук шешәдә «незамерзайка» да булган. Шешәләр әнә шул вакытта буталгандыр, дип фаразлый белгечләр. Вакыйга урынында «незамерзайка»дан бушаган шешә тапканнар, тикшерену анда метанол эзләре булуын күрсәткән. Ә менә сатып алынган спиртта әлеге агулы матдә табылмаган.

Бәхетсезлек бәхеткә юл ачты, дигән гыйбарә бар. Дөрес, бу очракта бәхет һәм бәхетсезлек төшенчәләре бик үк туры килмәсә дә, әлеге шау-шулы вакыйга «кайнар эз»дән җинаятьчеләр койрыгын эләктерергә ярдәм иткән. Күпләп агулану очрагыннан соң, полиция хезмәткәрләре сертификаты булмаган хәмер сатучының да, сатучылар чылбырының да эзенә төшкән. Ялган исерткеч эчемлекләр сатучы дүрт ир-ат тоткарланган.

Хәер, соңгы айларда ялган аракы эчеп күпләп агулану очраклары Россия төбәкләрендә еш ишетелә башлады. Әле октябрьдә генә Екатеринбургта метанол белән агуланып, 26 кешенең гомере өзелде. Ул вакытта ялган аракы сатуда шикләнелеп, Грузия һәм Азәрбайҗан кешеләре тоткарланды. Оренбургта да шуңа охшаш хәлләр булды. Контрафакт белән агуланган 64 кешенең 35е үлде. Әлеге фаҗигагә катышы булган тугыз кеше кулга алынды. Тикшерү эшләре әле дә дәвам итә. Тикшерүчеләр һәм оперативниклар Орск шәһәрендәге сәүдә-сатып алу базасы территориясендә 200 литрлы 11 мичкәдә спиртлы сыекча табып ала.

Шушы вакыйгалардан соң Россия Тикшерү комитеты башлыгы Александр Бастрыкин Баш тикшерү идарәсенә суррогат алкоголь белән агулану очракларын анализларга, ә ялган аракы эчеп агулану факты буенча кузгатылган җинаять эшләрен «тулысынча һәм һәрьяклап тикшерү өчен» Россия Тикшерү комитеты тикшерү идарәсенә тапшырырга күрсәтмә бирде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Тома сукыр калырга мөмкин»

Суррогат аракы белән агулану очраклары шушы берничә айда гына килеп чыккан проблема түгел, әлбәттә. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы этил спирты, алкоголь һәм составында спирт булган продукция җитештерүне һәм аның әйләнешен контрольдә тотуга юнәлдерелгән чараларны даими рәвештә башкара. Мәсәлән, быел ел башыннан исерткеч эчемлекләр сата торган 17 мең объект, 183 меңнән артык автотранспорт тикшерелгән. Легаль булмаган әйләнештән 197 мең литр ялган аракы һәм спиртлы эчемлекләр алынган. 92 җинаять ачыкланган.

Татарстанда легаль булмаган алкоголь продукциясен әйләнештән алу белән шөгыльләнүче тагын бер ведомство бар. Татарстан дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Рөстәм Арсланов әйтүенчә, быелның ун аенда шундый 30 мең литрдан артык продукция, шул исәптән суррогат әйләнештән алынган.

– Бервакытта да алкоголь продукциясен шәхси куллардан алырга ярамый. Андый эчемлекләрне лицензиясе, кассасы булган сату нокталарыннан гына сорарга кирәк, – ди җитәкче.

Рәсми булмаган кайбер чыганакларга караганда, суррогат Россиядә алкоголь базарының 70 (!) процентын алып тора.

Казанның 7 нче шәһәр клиник хастаханәсенең токсикология бүлеге мөдире Алия Насыйбуллина әйтүенчә, организмга эләккән метил спирты сәламәтлеккә бик зур зыян сала. Кеше хәтта үләргә мөмкин. Исән калган очракта да, тулысынча сукыраеп, яки бөерләренә зур авырлык килеп, инвалид калуы бар. Шулай ук бик нык агуланган кешеләр инсульт та кичерергә мөмкин.

– Метанол белән агуланганда, һәр сәгать кадерле. Бәйрәм вакытында агуланган яшьләр дә хастаханәгә соңлап мөрәҗәгать иттеләр. Хәмер кулланганнан соң 7–8 сәгать вакыт узган иде инде. Шуңа авырлыклар булды. Яшьләрнең сукыр калу куркынычы зур, – ди ул.

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе мәгълүматларына караганда, 5–11 ноябрьдә генә дә алкоголь һәм спиртлы сыекча эчеп агулануның 13 очрагы ачыкланган. Аннан алдагы атнада шундый 6 очрак теркәлгән.

Алия Насыйбуллина сүзләренә караганда, ел башыннан Татарстанда метанол белән агулануның барлыгы 14 очрагы теркәлгән. Гадәттә агуланучылар урта буын – 40–56 яшьлекләр икән. Һәм күпчелек очракта ялган аракы түгел, ә суыкта катмый торган сыекча эчеп агуланалар.

Минималь хезмәт хакы – 100–120 шешә аракы

Бу мәсьәләдә «ЦИФРРА» федераль һәм төбәк алкоголь базарларын тикшерү үзәге директоры Вадим Дробизның фикере игътибарга лаек. Аның сүзләре буенча, 2010 елга кадәр легаль булмаган продукция легаль заводларда җитештерелеп, легаль сәүдә нокталарында сатылды. 2010 елдан башлап 2016 елга кадәр бу алкогольне легаль базардан куып чыгардылар. Һәм 2014–2015 елларда Россия куллануучылары ике социаль төркемгә – легаль булмаган, суррогат продукция һәм легаль продукция сатып алучыларга бүленде. Һәм беренче төркемгә, гадәттә күпчелек уйлавынча, торыр урыны булмаган кешеләр түгел, ә аз керемлеләр керә, дип саный ул.

– Легаль продукция кулланучылар – уртача 25 мең сум тирәсе һәм аннан артыграк хезмәт хакы алып эшләүчеләр, – диде Вадим Дробиз «ВТ» хәбәрчесенә. – Алар сыйфатлы алкогольне бары тик лицензиясе булган кибетләрдән генә сатып ала. Ә легаль булмаган продукцияне җәмәгать туклану урыннары тәкъдим итә, аларның күпчелеге легаль алкоголь иселе астында ялган хәмер сата. Чөнки анда ЕГАИС системасы эшләми, сатылган һәр шешә күзәтеп барылмый. Ә лицензиясе булган кибетләрдә һәр хәмер күзәтү астында. Анда берничек тә ялган аракы була алмый.

Белгеч әйтүенчә, легаль булмаган суррогат аракы кулланучылар – аена 12–18 мең сум акча алып эшләүче кешеләр.

– Аз хезмәт хакы алып эшләүчеләр бер вакытта да 250 сумлык аракы алып эчми. Алар өчен иң кулай бәя – 100–120 сум. Моңа кадәр гел шулай булды. Моннан соң тагын 30 ел шушы хәл кабатланачак. Алар торыр урыннары булмаган кешеләр, мәңге айный алмаган исереклэр түгел. Алар – гадәти, нормаль кешеләр. Бу төркемгә керүчеләрнең якынча 20 миллионы легаль булмаган алкоголь куллана. Алар арасында бары тик 20 проценты гына – асоциаль (әхлаксыз, гамәлләре һәм үз-үзләрен тотышлары җәмгыятьтәге кагыйдәләрдән аерылып торган) кешеләр, – ди ул.

Вадим Дробиз әйтүенчә, моны массакүләм агулану очракларыннан чыгып та анализлап була.

– Казан, Екатеринбургтагы, Курган, Оренбург өлкәләрендәге, биш ел элек Иркутск өлкәсендәге вакыйгаларның барысында да нормаль, гадәти кешеләр агулануын күрдек, – ди ул. – Бу күренеш бер яки ике кеше агулану очракларына гына туры килми.

Белгеч фикеренчә, бары тик халыкның керемен арттыру һәм аз керемле кешеләргә сыйфатлы алкоголь җитештерү генә Россиядәге бер-бер артлы күзәтелә торган метанол белән агулану очракларын бетерергә ярдәм итәчәк.

> Халыкның минималь хезмәт хакы 100–120 шешәлек легаль аракыга тәңгәл булырга тиеш. Шул вакытта гына барысы да яхшы булачак. Башкача әйткәндә, әгәр кеше кулына ким дигәндә 25 мең сум акча ала икән, ул легаль булмаган продукция сатып алмаячак. Һәм бездә мондый продукция башка илләрдәге кебек күп дигәндә 10 процентны гына тәшкил итәчәк, – ди ул.

Шуңа күрә әлеге проблеманы көмешкә кайнатуны тыю, вакыт, урын, яшь чикләүләре, шешәгә яңа маркалар ябыштыру белән хәл итеп булмаячак. Чөнки бөтен легаль булмаган продукцияне җитештерү «идән астында» башкарыла, ул легаль булмаган сату нокталарында сатыла.

– Казандагы студентлар – Россиядәге сәясәтнең ачык мисалы, – дип саный ул. – Цивилизацияле илдә байлар һәм ярлылар өчен хәмер бар, ә Россиядә ул юк. Шуңа күрә Америка, Англия, Франция, Италия, Австралия, Аргентинада менә шундый үзенчәлекле сыекчалар белән агуланмыйлар. Ә Һиндстан, Африка кебек ярлы илләрдә агуланалар.

Казанда булган вакыйгадан соң Россия Дәүләт Думасы депутаты Солтан Хамзаев та илдә метил спиртын җитештерү һәм сатуны тыю инициативасы белән чыкты.

– Гражданнар сәламәтлеген саклау буенча гамәлдә булган закон нормалары берничек тә эшләми, – дип саный түрә. – 20–30 ел элеккеге кебек метил спиртын җитештереп сатуның хәзер инде ихтыяҗы юк. Аларны алыштырып була алырдай әйберләр бар. Профильле министрлыклар гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итә алмый. Теләсә нинди агу кебек, метил спирты да шундый җиңел юллар белән сатып алынырга тиеш түгел. Әлеге агу гражданнар кулына бик җиңел килеп ирешә. Аны бөтенләй җитештерми башларга кирәк. Моның авырлыгы юк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЕГЕТ БУЛЫЙК, ИРЛӘР!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Оясында ни күрсә…

Арча районы Казанбаш авылында яшәүче шагыйрә Гөлара Шәрипова – дүрт баһадир анасы. Безне исә ишле гаиләдә ир-ат булырга ничек өйрәтүләре кызыксындырды.

– Минем ир балага мөнәсәбәтем балачагымнан киләдер. Үз әтием дә сабыр, акыллы, эшчән кеше иде. Ул – бөтен яктан да үрнәк. Барлык ир-атларга да өлге итеп, аны күрсәтер идем. Шуңа күрә балаларымда да шушы сыйфатларны күрергә телим, – ди ул. – Ирем дә – бик акыллы кеше. Балаларга тәрбия бирү – безнең уртак эшебез. Мәсәлән, мин балаларыма әни дә, дус та, сердәш тә булырга тырышам. Әтиләре, усал булмаса да, аларны бер караштан тыңлата, ә балалар аны хөрмәтли белә. Аларга гел: «Әтиегез ни дияр? Әтиегез белән киңәшләшик әле», – дим. Гаиләдә атаны баш, үрнәк кеше итеп күрсәтергә кирәк дип саныйм.

Хатын-кыз ничек кенә мөстәкыйльлек яуларга тырышса да, тормыш дилбегәсе барыбер ир-ат кулында булырга тиеш, дип саный Гөлара ханым.

– Ир-атлар саны кимү мине бик борчый. Аларның гомере дә кыскарак бит. Җәмгыятьтә барыбер дә әйдәп баручы рольне ир-ат уйный дип саныйм. Җитәкчеләребез дә – ир-атлар бит, – ди ул. – Хатын-кыз ничек тә ир-ат ышыгындарак булырга тиеш. Гаиләдә дә, җәмгыятьтә дә. Көчле зат булып ир-ат калсын, соңгы сүзне ул әйтсен. Мин ирләрне сүккән, аларга тавыш күтәргән хатын-кызларны аңламыйм, мондый күренешләрне күңелемә бик авыр кабул итәм.

Үрнәк кирәк. Татарстанның атказанган артисты Фирдүс Тямаев фикеренчә, тормыш өчен мөһим булган сыйфатларны гаиләдәге әти күрсәтә ала.

– Минем өчен үрнәк кешем – әтием. Миңа әти: «Кешегә беркайчан да үзең башлап сукма, сүз әйтмә. Сиңа суксалар, авызларын ват», – ди иде. Горурлыгым, кирелегем мине ватанпәрвәр һәм чын ир-ат итә. Теләгем шул: балаларым да чын ир-ат булсын иде. Аллаһы Тәгаләдән көн дә, уларыма тәрмә юлы, бозыклык бирмә, дип сорыйм. Әти-әни өчен аннан да авыры юктыр. Ата-ана баласын начар булсын дип үстерми. Безнең өйдә төрдә каеш тора. Ул ике баланы болай гына тыеп торырга була диме? Бала әтисенең карашыннан куркып торырга тиеш. Хәзерге көндә без әнә шул курку булмаганга күрә аяныч хәлдә. Без хезмәт тәрбиясе алып үстек. Балаларны да тәрбияләргә тырышабыз. Телевизорны әллә нигә бер күрсәтәбез, телефоннарын алып куйдык. Улларымның төрле яклап үсүен телим, һәр өлкәдән нидер алсын, төрле шөгыльләр белсен ул, – ди җырчы.

Медальнең икенче ягы

Ә менә Казан дәүләт медицина академиясенең педиатрия һәм неонатология кафедрасы доценты, башкаланың 1 нче балалар хастаханәсе педиатрия бүлеге мөдире Илдус Лотфуллин мәсьәләгә башка яктан карарга өнди. «Кешеләр арасында кимчелекләр абруе төшсә, моңа, иң элек, шул кеше үзе гаепле. Бәлки, бу очракта да шулайдыр?» – ди ул.

Илдус Лотфуллин әйтүенчә, җәмгыятьтә ир-атны ир-ат җенесеннән булганы өчен генә дә күккә чөя торган мисаллар байтак.

kariev teatr.ru

Сан

Росстат мәгълүматларына ышансаң, Россиядә **78,626** млн хатын-кызга **68,123** млн ир-ат туры килә. Татарстанда ир-атлар **1655166** булса, хатын-кызлар – **2239341**.

– «Улым, улым» дип кенә йөрүләр, чалбар кигән өчен пьедесталның түренә менгезүләр – болар барысы да бар ич безнең халыкта. Кешене бозмыймы бу? Әлбәттә, боза. «Ир-атларны хөрмәт итмиләр» дигән проблема – уйдырма ул, минемчә. Безнең тормышта брутальлек, бөтен дөньяны дошман, көндәш итеп күрү артык күп. Дөнья күләмендә хатын-кызның роле зурая. Без моңа күпме генә карышсак та, «элеккечә яшисе килә» дисәк тә, иртәме-соңмы, бу үзгәрешкә кушылачакбыз, – дигән фикердә табиб.

Гаиләдә бала тәрбияләү мәсьәләсенә килгәндә, Илдус Лотфуллин кемгәдер «болай итегез, тегеләй тәрбия кылыгыз» дигән киңәш бирүләрне беркайчан да аңламадым, ди. Тәрбия үрнәгә кыз өчен дә, малай өчен дә бер инде ул.

– Беренчедән, баланы сүз белән түгел, дөрес үрнәк белән тәрбия кылу. Икенчедән, үз сабыеңның холкын, темпераментын аңлап, аңа хөрмәт күрсәтеп, аны үз табигатенә күрә үстерү. Бер бала тумыштан көрәшче була, икенчесе – уйчан, тирән фикерле, бәләкәй галим, өченчесе – елмаеп-көлеп торган артист. Барыбыз да төрле. Аллаһы Тәгалә хәят үзгәрсен, алга барсын өчен шулай иткәндер дә, бәлки. Үз табигатенә каршы тәрбияләнгән бала бәхетле кеше була алмый, минемчә, – дип уйлый Илдус Лотфуллин.

Күпләр чын ир-ат исемен йөртерлек затларның аз булуын инфантилизм һәм эмансипация чорына бәйләп, шуның җимешләре бу дип әйтергә дә мөмкин. Әлбәттә, моны инкарь итеп булмый. Күп сәбәпләрнең берсе ул. Тик бар гаепне дә шуңа сылтап, хатын-кызларның хокук даулавына гына аударып калдырырга кирәк түгел. Ир-ат үссен өчен шундый даирә, мохит тә булу мөһим бит әле. Ә бездә ул – юк дәрәҗәсендә. Балалар бакчасыннан башлап хезмәт коллективына кадәр ир-ат хатын-кызлар арасында көн күрә.

«Күп ирләр ялкау»

Казаннан 46 яшьлек Ралина ханым улын ялгызы үстергән. Ире белән 13 ел яшәгәннән соң, гаилә таркала: хәләле башка гаиләне сайлый. Бу вакытта улына 12 яшь була. Ә балаларын ялгызы гына үстерүчеләргә еш кына ике вазыйфаны бергә башкарырга – әни дә, әти дә булырга туры килә. Ралина ханым әйтүенчә, урталыкны саклаган очракта ир балага дөрес тәрбия бирергә була. Хәзер аның улына – 17 яшь.

– Мин улымны кирәк урында тиргәдем дә, кирәк урында яраттым да. Улым хатынша түгел. Ул миңа өй тирәсендә дә булыша, кызлар эше дип тормый. Атасы белән аралаша, аңа каршы котыртмадым, безнең арада булганнар сиңа кагылмый, дидем. Әлегрәк, сүз тыңламаса, атасына шалтырата идем. Әтисеннән курку булырга тиеш, – дип сөйли ул. – Серләрен сөйләргә дә ияләштердем, кызлар турында да сүз кузгатам. Акча эшләргә өйрәнде, мөстәкыйльлеге бар. Безнең өйдә син – бердәнбер ир-ат кеше, баш, хуҗа, дип өйрәтәм, хатынша булсын дип тырышмыйм. Мин эштән кайтканда, урамда күрешсәк, минем янга килеп, кочаклап-үбеп алырга да мөмкин ул. «Беркайчан да моннан оялма, бу – хөрмәт билгесе», – дип өйрәткән идем. Ана кешегә рәхәт бит!

Ралина ханым әйтүенчә, хатын-кызлар үзләре теләп баш булырга омтылмый. «Күп ирләр ялкау бит. Эшләргә тырышмыйлар. Аларга барысы да әзергә бәзер кирәк. Күбесенең бар эше – телефон тотып, диванда яту. Гаиләгә, хатынга игътибар бетә. Шуннан соң хатын-кыз идарәне үз кулына ала инде. Мин дә иптәшем барда аннан өмет иттем бит. Ә тормышны алып бару миңа калды. Мактану түгел, ким-хур булмаска, бөгелеп төшмәскә этәргеч булды», – ди ул.

Абруй югалмады, табигате үзгәрде

Тарихка күз салсак, электән үк ир-атка үз дәрәҗәсен югары тотарга дин ярдәм иткән, хөрмәтле, төп кеше, тормыш дигән фәнне өйрәтүче булып ата саналган. Бәлки, «Ир-ат нинди булырга тиеш?» дигән сорауга җавапны диннән эзләргә кирәктер? «Мәрҗани» мәчетенең икенче имамы Айморат хәзрәт Хаҗиев фикерен белештек.

– Ир баланы 4–5 яшьтә әни кешенең кирәгеннән артык кайгыртучанлыгыннан аерырга кирәк. Әниләр – нечкә күңелле кешеләр. Ир баланы «моны эшләмә», «таудан шума», «комлыкта уйнама» дип кисәтеп, һәр гамәле өчен куркып тора. Артык кайгыртучанлыктан нарасый анасының итәк астына керә дә, җебегәнрәк, үз фикерен әйтә алмаслык булып үсәргә мөмкин. Ир бала әтисенең яхшы гамәлләре үрнәгендә, аның кулы астында үсәргә тиеш, – ди хәзрәт.

«Ир-ат йә бәһасез, йә бер тиенгә тормый»

Малай-шалайдан ничек чын ир-ат тәрбияләргә? Буй җиткән егеткә күпчелекне хатын-кызлар тәшкил иткән җәмгыятьтә табигать биргән ирлек сыйфатларын ничек югалтмаска? Бу һәм башка сорауларга практик психолог **Марсель СҮЛТИЕВ** ачыклык кертте.

:: Марсель Рафаилович, психологик күзлектән караганда, чын ир-атны үстереп буламы?

– Беренчедән, иң элек, теләсә кайсы ир-ат кызларны яклаучы, саклаучы һәм хөрмәт итүче икәнен белергә тиеш. Бу – бик мөһим принцип. Димәк, әни кеше үзен баласы сакларга, якларга әзер булган хатын-кыз дәрәҗәсендә, лаеклы итеп тотарга тиеш. Әни баласына кычкыра, суга, кыйный икән, ир балада курку уяна. Психологик яктан ул үзен теләсә кайсы хатын-кыз алдында көчсез итеп тоячак. Шул рәвешле күп кенә ир-атлар эчүгә сабыша, гаилә кормас була. Гаиләсе булса да, алар еш кына таркала. Ир-ат хатын-кыз тарафыннан үзенең шәхси чикләре бозылганын сизә икән, дөньяда ул бернигә дә яраксыз булуын аңлый, шуннан җәфалана башлый. Болай булырга тиеш түгел. Ир-ат белән тәнлә итеп сөйләшә белергә кирәк.

Балаларны үбәргә ярамый, диләр. Ялган бу! Әгәр сез балагызны үбәсез, башкалар белән чагыштырмыйсыз, мыскыллямыйсыз, борчу-мәшәкатьләр белән шантажламыйсыз икән, ир-ат көчле дә була, ярату да тоеп үсә. Әниләргә шуны аңларга кирәк: баласын мыскыллау-түбәнсетү белән тәрбияләү дөрес түгел.

:: Хатын-кызлар даирәсе бик киң бит. Ир-ат табигать биргән сыйфатларын югалтмасын өчен нишләргә?

– Бу бары тик бер генә проблема аркасында килеп чыга: өйдә гаилә башлыгына карата тискәре караш күп. Эти начар, әти эчкече, аңа бәйле негатив сүзләр еш ишетелә... Нигә болай? Ә ник ир-ат эчә? Тамырына карасаң, шуны аңларга була: ир-ат эчүгә гаиләсендә ихтирам-ярату тоймаганнан сабыша. Мәхәббәттә негатив хисләр юк. Ир-ат үзен яратмаганнарын тоя икән, ул бу мәхәббәтне читтән эзли башлый. Аны башка гаиләдә табарга мөмкин.

:: Сер түгел, күп кенә гаиләләрдә ир баланы аналар ялгызы гына тәрбияли. Ата тәрбиясе күрмәгән малайлар киләчәктә «мәми авыз» булып үсмәсен өчен нишләргә?

– Күп кенә аналар аерылуның сәбәпләре турында уйланмый. Еш кына гүзәл затлардан: «Сез улыгызга үзегез кебек хатын теләр идегезме?» – дип сораганым бар. Уңай җавап ишеткән булмады әле. Димәк, һәркем үзенең нинди икәнен белә, ире белән ничек идарә иткәнен төшенә. Кешенең ата-анасына үпкә-рәнҗеше бар икән, ул үчен иреннән яки хатыныннан алачак. Әгәр иренә яки хатынына бар икән, агрессия сабыйга күчәчәк.

Мондый әниләргә шуны аңларга кирәк: балалар – мөстәкыйль затлар. Аларны мөстәкыйльлеккә өйрәтергә кирәк. Ялгызы гына бала үстергән аналарга мин: «Сез бит мәңгелеккә килмәгән. Кайчан да булса бу дөньядан китәргә туры килер. Балагызны үзегезгә бәйле итсәгез, сездән куркып торырлык итеп тәрбияләсәгез, сездән соң да ул шулай куркып торырлык хатын-кыз табачак», – дим. Балага ташлап киткән атасы турында начар сөйләргә ярамый. Үскәч, үзе нәтиҗә ясар.

:: Инкыйлаб чоры ир-атны да, хатын-кызны да хокукый яктан берникадәр тигезләде. Ир-атларның җәмгыятьтәге дәрәҗәсе төшү шуннан башланмадымы икән соң?

– Юк, аннан гына түгел. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасының 1948 елгы трактатын укып карасагыз, барысын да аңларсыз. Хатын-кыз ир-атны коралмас дәрәҗәгә җитсен, үзен өстенрәк куйсын өчен эшләнгән бу. Соңрак хатын-кызлар манифесты – феминизм барлыкка килә. Анда язылган сүзләрне китереп тору да куркыныч. «Әгъзасыннан кала берни белән дә мактана алмый», «тизәк белән бер» дигән сүзләр бар анда ир-атлар турында.

Еш кына ир-атның хатын-кызны яклаучы икәнен онытабыз. Һәм ул бары тик үзенә зыян салмаган гүзәл затны яклаячак.

Шунысын аңлагыз: мин ир-ат иң яхшысы димим. Хатын-кызлардан да гүзәл зат юк! Бу хакта барлык диннәрдә дә, тарихи чыганакларда да әйтелә. Ислам динендә, хатын-кыз 44 кг 928 г алтынга тиң диелә. Менә син дә шул кадәр алтынга тиң, димәк! Ир-ат турында мондый сүз юк. Мантыйк буенча, йә алар – бәһасез, йә бернигә дә тормый диган сүз бит инде бу.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

19 ноябрь – Халыкара ирләр көне. Бу көннең максаты – ир-атларның җенес ягыннан кимсетелүенә, гаиләдә һәм бала тәрбияләүдә ролена, аларның сәламәтлеген саклауга, эмоциональ, физик, социаль иминлегенә игътибар җәлеп итү. Шул уңайдан малайлар – асыл ир-егет булып җитешсен, ә ир-атлар табигать биргән егетлек сыйфатларын югалтмасын иде дигән теләктә калабыз.

ЯШЬ ФЕРМЕР РӘНИС ШӘРИФУЛЛИН:

Безнең күркәләр «Авыл көе»н ярата

Рәнис белән шактыйдан таныш без. Мәктәпне тәмамлап, Казанның энергетика көллиятендә укыган дәверендә авылга кайтты да үз эшен башлап җибәрде 22 яшьлек егет. Инде менә өч ел Мамадыш районының Дусай авылында кошчылык белән шөгыльләнә.

Дусай кечкенә авыл дип санала. Ләкин Рәнисне бу гына куркытмый, билгеле. Төп нигезне саклап калуны үз бурычы итеп кабул итә ул. «Аллаһы Тәгалә кушмаса, агачтагы яфрак та селкенми, дип әйтәләр бит әле. Менә мин дә, шулай язмаган булса, үз эшемне башлый алмас идем. Кечкенәдән авыл хуҗалыгы өлкәсе якын булгач, үзебезгә кайттым», – ди. Туган авылына юкка чыгу куркынычы янавына да борчыла. Эше булса, кешесе дә булыр иде, дип өметләнә.

Рәнис Шәрифуллин дәүләт программаларында катнашмый, кошчылык белән үз көченә таянып шөгыльләнә башлый. «Иң зур терәгем – якыннарым. Күркә үрчетергә телим, дип әйткәч, әти-әнием шундук бу фикеремне хуплады. Хәзер дә бөтен эшне бергәләп башкарабыз», – ди егет.

Шундый яшь егет бу зур эшкә алынудан курыкмады микәнни, диярсез сез. «Бу дөньяга яшәргә дип килгәч, барысын да эшләп карарга кирәк. Эшләп карамаган килеш, булдырып та, булдырасыңны белеп тә булмый. Аннан соң, яшь чак – җүләр чак, диләр бит. Чыннан да шулай ул. Яшьрәк булган саен, курку хисе дә азрак була», – ди Рәнис.

Эшен 100 күркәдән башлаган. Соңыннан бу санны 150гә җиткергән. Бүген менә 450 баш күркә асрый. «Безнең эштә иң мөһиме – чисталык», – ди ул. Рәнис сату эшләрен күбесенчә «Инстаграм» аша башкара, шуңа да ул үстергән күркәләрнең фотосурәтләрен еш күргәлим. Ышанырсызмы, юкмы – белмим, ләкин канәгать булулары йөзләренә чыккан аларның. Чистартып, ашатып тору өстенә, хуҗаң тальянда уйнап кәефне дә күтәргәч, яшәүдән ничек канәгать булмыйсың ди! Бу кадәр тәрбия күргәндә, җырлап та җибәрерсең. Ә Рәнис тальянда бик оста уйный. «Безнең күркәләр аеруча «Авыл көе»н ярата», – ди. Авылда үскәнгәдер инде. Егетнең уйнап җырлаганы сарай эчендә генә калмый, авылдашларына да барып җитә. Концертлар булганда, аларда да катнашырга вакыт таба икән.

Рәнис һәм ул сата торган күркә ите турында Әлмәттә дә, Казанда да яхшы беләләр. «Күркә ите башкаларга караганда файдалырак. Моны шәһәр халкы яхшырак аңлыймы икән соң – күбесенчә алар сорый. Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Казан – барысына да үзем илтеп бирәм. Анысы өчен акча сорамыйм. Сатып алучыларга уңайлы бит», – ди егет үзе.

19 яшендә үз эшен булдырган Рәниснең үзе кебекләргә әйтер сүзе дә бар. «Кеше үзе яраткан, күңеленә яткан эш белән шөгыльләнсә, аның нәтиҗәсе дә булачак. Кеше сине сөйләп туймас ул, читләрнең ни әйтәсен уйлап торыр чак түгел, йөрәгеңне тыңларга кирәк», – ди.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бер өйдә... бер кеше

Тормыш тоташ югалту-табышлардан тора. Университетка укырга кергәндә тулай торакта бер ай тирәсе бергә яшәгән Чүпрәле кызы Наилә белән дә ничә югалтышып, ничә табыштык инде. Санаулы көн эчендә ничек шулкадәр якыная алганбыздыр, белмим. Кызганычка, ул укырга керә алмады, четердәп торган мишәрлеге зыян салды дип беләм.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Иң беренче татарча инша язасы иде. Ә аңарга эчтәлек өчен дә, хата өчен дә бер генә билге куела. Әйтик, сөйләшә урынына, иялэнгәнчә, сүләшә дип язса, шуның ише вак-төяктән дә билге киметерлек хаталар җыю тиз шул. Юкса, сөйләм теле дә, язма теле дә шулкадәр бай иде үзенең. Соңыннан ул язган хат-открыткаларны укып, мин гел: «Их, бер дигән журналист чыга иде бит бу кыздан, әрәм булды», – дип уфтана идем. Ул әллә ни уйланып тормады, эшкә урнашты. Мин көндезгедә укыганда әле сирәк булса да очраша идек, аннан хат-открыткалар языштык. Берничә елдан ул, районташына тормышка чыгып, авылга кайтып китте. Элемтәләр өзелде.

Моннан ун еллар элек өй телефоным шалтырый: «Кызый, син шул Гөлсинәме?» – ди. Ул чакта «Ватаным»да чыккан язмалар аша табыштык. Берничә ел аралаштык. Аннан кайсыбызныңдыр номеры алышынды, тормыш мәшәкатьләре дә сәбәпче булгандыр инде, аралар тагын өзелде.

Беркөнне тагын өй телефоны шалтырый. Ике сүз әйтүгә таныдым – Наилә иде. Сагынышканбыз. Озаклап сөйләштек. Үзебез, балалар, ковидтан соң, билгеле, икебез дә авылда яшәүче буларак, авыллар язмышын да читтә калдыра алмадык.

– Сездә ни хәлләр соң анда? – ди Наилә. – Бездә авылда яшьләр калмады диярлек инде. Барысы да читкә китеп эшли. Ульян бик якын булу да сәбәпчедер инде. Анда да, Мәскәүгә барып та эшлиләр. Без яшәгән урам элек гөрләп тора иде. Хәзер өй саен – бер кеше. Икелесе бик сирәк...

– Ничек инде өй саен бер кеше? – дип аптырыйм. Ул исемләп саный.

– Бездә, – мин әйтәм, – өй саен кимендә өч кеше. Күбесендә мәктәп, бакча балалары булган яшь парлар да бар... Берьялгызы гына яшәгән кеше юк, – дим.

Бу юлы инде Наилә аптырый.

– Әй, сездә элек тә яшьләр авылда күпләп кала иде бит. Колхозыгыз да көчле, алдынгы булды, юлларыгыз да шәп иде бугай, – ди.

– Яшьләрнең күпләп авылда калуы да хак, колхозның алдынгы булуын да дөрес хәтерләгәнсең, тик юлларыбыз мактанырлык түгел иде. Бигрәк тә безнең ике авыл арасы язын-көзен, әле яңгырлы җәйдә дә танкта гына йөрерлек була иде. 1995–1996 елларда асфальт җәелде дә, шуннан соң юл проблемасын оныттык, – дим.

– Сездә колхозларны бетермәделәр шул, – ди Наилә. – Бездә шуннан башланды. Колхозы ныкның авылы нык инде аның.

– Әле без авыл бетә, авыл картая, быел бер генә бала туды, аннан берничә тапкыр артык кеше гүр иясе булды, дип кайгырабыз, – дим. – Тик барыбер бездә дә элекке авыл түгел, бер-беребезгә йөрешүләр дә юк, һәркем үз «казаны»нда кайный...

– Без дә йөрешмибез шул. Каршы яктагылар белән иртә-кич: «Шөкер, тәрәзәсендә уты бар, исән-имин икән», – дип аралашабыз, кирәктә телефоннан шалтыратышабыз, – ди Наилә. – Ялларда, бәйрәмнәрдә балалар кайта, бездә дә урамнарга ямь керә...

Нигәдер өй саен бер генә кешеле итеп күрәсе килми авылымны. Күзалларга да куркыта. Һич югы, бүгенгебез шөкер итәрлек иде бит әле. Бүген авылдан Казанга, Мәскәүгә йөреп эшләүчеләребез юк, элеккечә әйтсәк, шул колхозда, район эчендәге хуҗалык-оешмаларда эшләп, көн күрәләр. Үз хуҗалыкларында күп итеп мал-туар асрап, тырышып эшләп, муллыкта яшиләр. Гел шулай булыр кебек тоела...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

22 ноябрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.30, 22.40 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 00.00 «БАБЬЕ ЛЕТО» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
17.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Реальная экономика» 12+
22.30 «Вызов 112» 16+
00.50 «Соотечественники» 12+
01.15 «Черное озеро». Пять пуль за газировку 16+
01.45 «Путь» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.00 «Башваткыч» 6+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
19.10 «Иннополис. Спец. репортаж Алины Сулеймановой» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Онытa алмыйм» 6+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.05, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «МОСГАЗ. ДЕЛО №8: ЗАПАДНЯ» (S) 16+
22.30 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.25 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 «Познер» 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55, 02.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.20 «СТЕНОГРАММА СУДЬБЫ» 16+
23.35 «Вечер» 12+
04.05 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 15.05 Новости
06.05, 21.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
10.00 Керлинг. Чемпионат Европы. Женщины. Россия – Швейцария. Прямая трансляция из Норвегии
12.35 «Есть тема!» Прямой эфир
13.35 Спец. репортаж 12+
13.55, 15.10, 04.00 «ВЫСТРЕЛ» 16+
18.30 «Громко» Прямой эфир
19.25 Хоккей. КХЛ. «Спартак» (Москва) – «Йокерит» (Хельсинки). Прямая трансляция
22.30 «Есть тема!» 12+
22.50 Тотальный футбол 12+
23.20 «НОВЫЙ КУЛАК ЯРОСТИ» 16+
01.05 Профессиональный бокс. Трансляция из Москвы 16+
02.00 Прыжки на батуте и акробатической дорожке. Чемпионат мира. Трансляция из Азербайджана 0+
03.10 «Громко» 12+
03.55 Новости 0+

НТВ

05.00 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.25 «За гранью» (S) 16+
17.30 «ДНК» (S) 16+
18.35, 19.40 «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» (S) 16+
21.20 «ПО ТУ СТОРОНУ СМЕРТИ» (S) 16+
00.00 «ВЫСОКИЕ СТАВКИ. РЕВАНШ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «Реальная мистика». «Кассовый аппарат Купидона» 16+
07.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Экспресс-приворот» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55, 19.00 «ДОКТОР НАДЕЖДА» 16+
23.00 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.05 «Реальная мистика» 16+
02.55 «Верну любимого» 16+
03.20 «Порча» 16+
03.45 «Знахарка» 16+
04.10 «Понять. Простить» 16+
05.00 «Тест на отцовство» 16+
05.50 «Домашняя кухня» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «ЛЕТО ВОЛКОВ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня
09.20, 13.25, 18.30 «Специальный репортаж» 12+
09.40, 01.40 «ДЕТИ ДОН КИХОТА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.50, 14.05 «СМЕРШ. УМИРАТЬ ПРИКАЗА НЕ БЫЛО» 16+
14.00 Военные новости
18.50 «Освободители». Док. сериал. «Брянск. Они не пропали без вести» 16+
19.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №80» 12+
20.25 «Загадки века». Док. сериал. «Убить Фиделя Кастро». Премьера! 12+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ЖИВИ И ПОМНИ» 16+
02.55 «Зафронтовые разведчики». Док. сериал 16+
03.35 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
03.45 «ОБЪЯВЛЕНЫ В РОЗЫСК» 16+

23 ноябрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.30, 22.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 23.30 «БАБЬЕ ЛЕТО» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Рыцари вечности» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 « Не от мира сего...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Таяну ноктасы» 16+
17.00, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Динамо» (Р). Прямая трансляция6+
22.30 «Вызов 112» 16+
00.20 «Видеоспорт» 12+
00.45 «Соотечественники». «Солнечные сосны» Шишкина 12+
01.10 «Черное озеро». Пять пуль за газировку. Возмездие 16+
01.35 «Путь» 12+
01.50 «Не от мира сего...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 22.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 22.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.50 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
19.30 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Ак барс» (Казан) – «Динамо» (Рига). Трансляция – Казаннан 6+
23.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Онытa алмыйм» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.15, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «МОСГАЗ. ДЕЛО №8: ЗАПАДНЯ» (S) 16+
22.35 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.30 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.10 «Николай Добронравов. «Как молоды мы были...» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55, 02.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
18.40 «60 минут» 12+
21.20 Русская серия. «СТЕНОГРАММА СУДЬБЫ» 16+
23.35 «Вечер» 12+
04.05 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.35, 15.15 Новости
06.05, 16.25, 19.55, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.40 Спец. репортаж 12+
09.25 «Игры Титанов» 12+
10.20 Смешанные единоборства. AMC Fight Nights. Вячеслав Василевский против Богдана Гуськова. Трансляция из Москвы 16+
10.35 Смешанные единоборства. RCC. Вячеслав Василевский против Вискарди Андраде. Трансляция из Екатеринбурга 16+
11.00 «МатчБол»
11.35 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.20, 04.00 «ВЫСТРЕЛ» 16+
16.55 Хоккей. КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) – «Торпедо» (Нижний Новгород). Прямая трансляция
19.15 Профессиональный бокс. Джамал Джеймс против Раджаба Бутаева. Бой за титул чемпиона мира по версии WBA. Трансляция из США 16+
20.30 Футбол. Лига чемпионов. «Вильярреал» (Испания) – «Манчестер Юнайтед» (Англия). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. «Мальмё» (Швеция) – «Зенит» (Россия). Прямая трансляция
01.40 «Есть тема!» 12+
02.00 Футбол. Лига чемпионов. «Челси» (Англия) – «Ювентус» (Италия) 0+

НТВ

05.00 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.25 «За гранью» (S) 16+
17.30 «ДНК» (S) 16+
18.35, 19.40 «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» (S) 16+
21.20 «ПО ТУ СТОРОНУ СМЕРТИ» (S) 16+
00.00 «ВЫСОКИЕ СТАВКИ. РЕВАНШ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «Реальная мистика». «Любовник по наследству» 16+
07.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.55, 10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Отвращение» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55, 19.00 «ДОКТОР НАДЕЖДА» 16+
23.00 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.05 «Реальная мистика» 16+
02.55 «Верну любимого» 16+
03.20 «Порча» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ОБЪЯВЛЕНЫ В РОЗЫСК» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня
09.30 «БЛОНДИНКА ЗА УГЛОМ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25, 18.30 «Специальный репортаж» 12+
13.50, 14.05 «МОРПЕХИ» 16+
14.00 Военные новости
18.50 «Освободители» 16+
19.40 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Николай Абрамов 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.40 «ФРОНТ БЕЗ ФЛАНГОВ» 12+
02.45 «Зафронтовые разведчики». Док. сериал 16+
03.20 «Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.50 «МОРПЕХИ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 22–28 НОЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04) Җыелып килгән проблемаларның очына чыгарга кирәк хәзер: юкса соңга калырга мөмкинсез. Беркемне дә тәнкыйтьлисе түгел, үзегезне белегез, дип кисәтә йолдызлар. Атнаның икенче яртысында берара уй-хыяллар һәм хис-тойгылар диңгезенә чумып алырсыз.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05) Акча мәсьәләсендә берникадәр кыенлык килеп чыгарга мөмкин. Кара кайгыга батмагыз – экономияләү турында гына азмы-күпме баш ватарга кирәк бугай сезгә... Сәфәр-сәяхәтләрдән баш тартып торыгыз: хәзер сез өйдә кирәк.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06) Бердәнберегездән бүләк яки матур гына сюрприз көтегез. Суык тидерү куркынычы бар. Пандемия чорында нәрсә икәнен дә аерып булмый. Шуңа күрә, авырып китмәс өчен, җылырак киенеп йөрергә, иммунитетны ныгытырга тырышыгыз.

КЫСЛА (22.06 – 22.07) Үтә катлаулы булып тоелган бер проблемагыз уйламаганда-көтмәгәндә бик җиңел хәл ителеп куяр. Кешеләр белән уртак тел таба беләсез – шуңа шулай. Атна ахырында тормышыгызга уңай бер яңалык үтеп керүгә өметләндерердәй хәбәр ишетерсез.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08) Игътибар үзегездә калырга хыялландыгызмы? Рәхим итеп, калыгыз! Ләкин башыгызга таҗ гына киеп куймагыз, юкса тирәгездәгеләр үзегезне бик тиз җиргә төшермәгәе.

КЫЗ (24.08 – 22.09) Атна сәеррәк кенә яңалыклардан башланыр. Юкюк, начар дип әйтеп булмый аларны, әмма... Эшегездә бик мөһим чор башланырга тора. Югарырак вазыйфага күчерүләре бар, шул сәбәпле бераз гына дулкынланырга, икеләнеп калырга туры килмәгәе.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10) Көз моңсулыгы үзегезне биләп алырга маташа сыман. Аннан котылу өчен дусларыгыз белән күбрәк аралашыгыз, өйдәгеләр белән җылырак мөнәсәбәтләр корыгыз. Уяурак булыгыз: бер көнче адәм үзегезгә аяк чалырга йөри сыман.

ЧАЯН (24.10 – 22.11) Иске эшләрегезгә әйбәт кенә нокта куеп, яңаларын башлап җибәрү өчен искиткеч шәп чор. Тик якыннарыгыз белән кат-кат киңәшләшкәч кенә эшкә тотыныгыз. Атна ахырында тормышыгызга әйбәт кенә бер яңалык үтеп керүгә җирлек барлыкка килер.

УКЧЫ (23.11 – 21.12) Беренче урында – эш. Шул сәбәпле шәхси тормышта бераз гына чатаклык булып алмагае. Аның каравы кесәгезгә әйбәт кенә премия керер. Атна ахырларына таба бераз туарылып алсагыз әйбәт булыр, юкса киеренкелек сәламәтлеккә зыян салырга мөмкин.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01) Күңелгә сары май булып ятардай хәлләр бер-бер артлы чыгып кына торыр. Кайберләре хәтта матди хәлегезгә әйбәт йогынты ясар. Кызыксызрак, авыррак эшләрне ахырга калдырсагыз да, берни булмас.

СУКОЯР (21.01 – 19.02) Күңел түрендә йөрткән бер хыялыгызны тормышка ашырып куанырсыз. Өстәвенә әле эшегездә дә көтмәгәндә генә дигәндәй мактаулы хезмәткәргә әйләнеп куярсыз. Тегеннән-моннан акча эшләү тәкъдименә килгәндә, бик ашыкмый торыгыз, тәкъдим итүчеләре бик ышанычлы түгел бугай...

БАЛЫК (20.02 – 20.03) Авызны кайчан ачарга, кайчан ябарга икәнен яхшы белгәнлектән, шөкер, өегездә кара тавыш чыкмый калачак. Хезмәт урыныңдагы күтәренкелек үзегезне бик нәтиҗәле эшләүгә этәрәчәк.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Белдерү

ФАТИРЛАР РЕМОНТЛЫЙБЫЗ
+79179024638

ЙОГА КЕШЕЛӘРГӘ ЫШАНЫЧНЫ АРТТЫРА

Йога – җанга да, тәнгә дә дәва. Казандагы «Лотос» йога үзәгендә булып кайтканнан соң, шундый нәтиҗәгә килдек. Ул гына да түгел, йога картлыктан да менә дигән дәва икән. Безнең белән бер бүлмәдә шөгыльләнгән кешеләрнең иң өлкәненә 74 (!) яшь иде. Иң борынгы дәвалау ысулларының берсе саналган йога тагын нәрсәләрдән шифалы икән? «Лотос» йога үзәге башлыгы Анастасия ТЕТЕРИНА белән шул хакта сөйләштек.

:: Йога нидән гыйбарәт? Ни өчен йога белән шөгыльләнергә кирәк?

– Күпләр йоганы ниндидер гайре табигый, борынгы методика итеп кабул итә. Бу чынлыкта да шулай. Әмма хәзер ул заманга яраклаштырылган. Йога белән шөгыльләнгән тәҗрибәле белгечләр, Һиндстаннан Европага килгәч, бирелә яшәүчеләрнең индуслардан бик нык аерылганын күргән. Аларның мускулларын катырып, һәрчак киеренке халәттә йөргәненә игътибар иткәннәр. Бүген дә күбебез әнә шундый халәттә яши. Бу аз хәрәкәтләнү, утырып эшләү аркасында килеп чыга. Йогадагы күнегүләр ярдәмендә, иң беренче чиратта, әнә шушы киеренкелек югала. Йога безне үз тәнебезне тоярга, аның белән гармониядә булырга өйрәтә. Уй-фикерләребезне, дөньяга карашыбызны да үзгәртә ул.

:: Сезнең студиядә йоганың нинди төрләре белән шөгыльләнергә мөмкин?

– Йога белән яңа гына таныша башлаган кешеләр өчен махсус программабыз бар. Моннан тыш гамактагы йога, Б.К.С. Айенгар ысулы буенча, дживамукти-йога, хатха-йога кебек күптөрле юнәлешләрдә эш алып барабыз. Сәламәт арка, хатын-кыз сәламәтлеге класслары да бар. Йөкле хатын-кызлар өчен аерым программа буенча эшлибез. Күргәнегезчә, бездә фәкать хатын-кызлардан гына торган төркемнәр дә бар. Шуңа күрә бездә мөселмәләр дә курыкмыйча шөгыльләнә ала. Йогага йөрүчеләр арасында ир-атлар бармак белән генә санарлык. Бездә балалар өчен йога дәресләре каралган. Алар уен рәвешендә уза. Абонемент алган кеше бездәге барлык йога төрләрендә дә үзен сынап карый ала.

:: Йога нинди авырулардан дәва?

– Иң беренче чиратта, арка авыртулары булган кешеләргә файдалы. Дөрес, аларга хәлләре әйбәтләнеп торган вакытта гына шөгыльләнергә рөхсәт ителә. Йога ярдәмендә авыруның менә шушы ремиссия вакытын шактый озайта алар. Даими рәвештә йога белән шөгыльләнүчеләр арасында аркадагы авыртудан тулысынча котылган кешеләр дә бар. Безнең төп максат кул-аяк хәрәкәте, эше ярдәмендә умырткалыкка кадәр барып җитеп, аны сәламәтләндерүдән гыйбарәт. Артроз, коксартроз, остеохондроздан интеккән кеше дә йоганың шифасын тоя. Йога белән шөгыльләнгән кешенең баш авыртулары кими, күз күрүе яхшыра.

:: Йога белән шөгыльләнү катгый тыелган очраклар бармы?

– Яман шеш вакытында катгый тыела. Ник дигәндә, күнегүләр ясаганда тәнебез бик нык кыза, кан әйләнеше, лимфа бизләре эшчәнлеге активлаша. Шуңа күрә метастаз организмга тизрәк таралырга мөмкин. Ниндидер хроник чирләре булган кешегә йога белән шөгыльләнгәндә сак булырга кирәк. Хатын-кызларның күрем вакытларында да махсус күнегүләр генә ясарга ярый. Операция кичергән кешеләргә дә табибтан алган белешмәсе булган очракта гына шөгыльләнергә рөхсәт ителә.

:: Йога кешенең холкын да үзгәртә, диюләре дөресме?

– Әлбәттә! Көндәлек тормышта күпләр киеренке халәттә, бөкрәебрәк йөри. Мондый халәттә күкрәк читлеге үзеннән-үзе ябыла. Нәтиҗәдә, кешеләргә ышаныч бетә. Йогадагы күнегүләр ярдәмендә ул, киресенчә, ачыла. Шул рәвешле кешеләргә ышаныч та барлыкка килә. Күкрәк читлеген ачу – йөрәгебезне дә ачу дигән сүз. Шуңа күрә дәрес вакытында күпләр күз яшьләрен тыя алмыйча елап җибәрә. Бөтен киеренкелек югала. Йогада кулда, башта басып тора торган махсус күнегүләр бар. Аны айлар, еллар дәвамында өйрәнеп кенә эшлибез. Бу күнегүләр дөньяның астын өскә килү белән бер. Кеше алар ярдәмендә бөтен куркуларын җиңә, дөньяга бөтенләй башка күзлектән карый башлый. Без үз тәнебезне тоя белмибез бит. Моңа безне махсус өйрәтүче дә юк. Йогага килгән кеше исә үзенең һәр күзәнәгенә кадәр сизә башлый. Шуңа күрә безнең бүлмәләрдә көзгеләр дә юк. Кеше төп игътибарны үзенә, эчке дөньясына юнәлтсен өчен шулай.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Йога ябыгырга да ярдәм итәме?

– Без ябыгу өчен азрак ашарга, спортзалга йөрергә, кардиокүнегүләр ясарга кирәк дип уйларга күнеккән. Бу дөрестән дә шулай. Ләкин йога кешене үз-үзе белән гармониягә китерә. Ә үз-үзе белән гармониядә булган кеше һәр адымын ясар алдыннан үзенә «Бу миңа кирәкме?» дигән сорау бирәчәк. Шул рәвешле ул күп нәрсәдән, шул исәптән чамасыз ашаудан баш тарта ала. Шуңа күрә йога белән шөгыльләнгән кешенең гәүдәсе күзгә күренеп яхшыра, артык килограммнары да югала. Йогадагы күп кенә күнегүләр корсак, ян-яклардагы майларны да «яндыра».

Ничек әзерләнергә?

- Күнегүләр ясарга ике-өч сәгать кала ныгытып ашамау хәерле.
- Дәрескә кадәр һәм аннан чыккач, бер стакан җылы су эчеп куйсаң да яхшы.
- Киҗе-мамык материалдан тегелгән уңайлы киемнән шөгыльләнсәң яхшырак. Ул һава да йөртә, шумавы белән дә рәхәт.
- Йогага килгәндә, күтәренке рух һәм яхшы кәефне дә үзегез белән алырга онытмагыз.

:: Шөгыльләнү өчен яшь чикләве бармы?

– Бу сорауга танылган йога белгече Аенгар сүзләре белән җавап бирәсе килә. «Ничә яшьтә шөгыльләнә башлавыгыз мөһим түгел. Даими рәвештә шөгыльләнгән очракта, бу эшкә 80 яшьтә тотынган кеше дә тиешле нәтиҗәгә ирешәчәк», – ди ул. Йогада иң авыры – идәнгә келәм җәю. Бар да әнә шуннан башлана.

Гаймориттан котылып була

Чөгендер. Табиблар еш кына борынны тозлы су белән юдырырга киңәш итә. Әлеге процедураны өй шартларында әзерләнгән кушылма белән дә башкарып карарга була. Моның өчен чөгендер согын тоз һәм су белән болгатабыз. Борынны көнгә 3 тапкыр юдырырга кирәк.

Глицерин һәм мумие. 200 граммлы 10 таблетка мумиены 7 грамм глицерин, 20 миллилитр су белән болгатабыз. Борынга көнгә 3 тапкыр тамызабыз. Дәвалау курсы 21 көннән артмаска тиеш.

Тырнак гөл (календула) төнәтмәсе. Мондый төнәтмә даруханәләрдә сатыла. 250 мл суны 35 тамчы төнәтмә белән катнаштырабыз. 2 атна дәвамында иртәкич борынга тамызабыз.

Үзем сынадым

Остеохондрозны җиңдем

Остеохондроздан интегәм. Соңгы арада бер ысулның файдасын күрә башладым. Газета укучылар белән дә бүлешим әле. 10 аш кашыгы тоз өстенә 20 аш кашыгы үсемлек мае агызабыз. Яхшылап болгатып, берничә көнгә куеп торабыз. Нәтиҗәдә ак төстәге масса барлыкка килергә тиеш. Аны һәр көнне муенга сылап, массаж ясыйбыз. Башта ике-өч минут кына, һәр көнне икешәр минут өстәп барып, егерме минутка кадәр арттырабыз. Массаж ясап бетергәч, муенны дымлы җылы сөлге белән сөртәбез. Ун процедурадан соң алга китеш сизәрсез. Дәвалану барышында матдәләр алмашы да яхшырачак.

Фәния ХӘМИДУЛЛИНА. Чаллы

Су гына, димә

- Иртән уянгач та эчелгән 1–2 стакан су эчке әгъзаларны уятып җибәрә, актив эшчәнлеккә көйли.
- Сәламәт булу өчен тәүлегенә кимендә 2 л су эчәргә кирәк. Аны кайчан эчү дә мөһим.
- Ашарга ярты сәгать кала эчелгән бер стакан су ашкайнату эшчәнлеген яхшырта.

- Ванна кергәнче яки мунчага барыр алдыннан эчелгән бер стакан су кан басымын төшерергә ярдәм итәчәк.
- Төнгә каршы 1 стакан су эчегез. Тыныч йокларсыз, инсульт һәм йөрәк өянәге булу куркынычын күпкә киметә.
- Йоклаганда аягыгызны көзән җыера икән, бу очракта да ятар алдыннан су эчү файдалы булыр.
- Иртәнге, төшке, кичке аш алдыннан 1–2 стакан чиста су эчеп, 3 айда 4 килога ябыгып була. Су артыгын ашарга мөмкинлек бирми, порцияләрне үзең дә сизми кимәтә башлыйсың.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Аш-су

Бик тәмле эремчек бәлеше

Җырчы Рамилә ХӘЙРЕТДИНОВАның әнисе рецепты

Камыры өчен кирәк булачак:
3 стакан кайнаган су, ярты стакан үсемлек мае, ярты стакан шикәр комы, бераз гына тоз, 50 грамм чамасы чүпрә, онны хуҗабикә үзе чамалап сала.

Эчлеге өчен: ярты кило эремчек, 4–5 йомырка, 2 аш кашыгы каймак (бу ризыклар авылныкы булса – тагын да яхшырак), ярты стакан шикәр комы, бераз гына ванилин.

Искиткеч тәмле, йомшак, хуш исле эремчек бәлеше килеп чыга!

СҮЗ УҢАЕННАН

Эчлеге сыек булган «ачык» бәлешләр (әйтик, җиләк, шомырт бәлеше) гадәттә табага агып чыгып, камырны боза. Моны булдырмас өчен нишләргә?

◆Сыек эчлеккә печенье яки сухарины онга әйләнгәнче төеп салырга мөмкин. Өстенә төелгән дарчин (корица) сипсәң, тагын да әйбәтрәк.

◆Бәлеш эченә берничә урынга кыш эчле кыска токмач («перья») урнаштырырга да була. Болай эшләгәндә, җиләк согы кайный башлагач, токмач эчендә өскә күтәреләчәк һәм табага агып чыкмаячак. Бәлеш пешкәч, токмачны алып куябыз да – шуның белән шул. Бу очракта токмачның каты сортлы бодайдан җитештерелгәне әйбәтрәк.

◆Эчлек өстенә 1–2 чәй кашыгы манный ярмасы сибүчеләр дә бар. Сокны үзенә сеңдереп, эчлекнең агып чыгуын булдырмый ул. Манный урынына төелгән солы лачаулары кулланырга да мөмкин. Бәлештә ярманың тәме сизелми.

Киңәш

Гөлләргә – сихәтле бәлзәм

Водород перекисе сыекчасының гөлләр өчен бик тә файдалы булуын беләә идегезме? Яңгыр суын алыштыра икән ул! Елның салкын чорында 1 литр җылы суга (хлорлы суны бер тәүлек тондыру әйбәт) 1 аш кашыгы 3 процентлы перекись кушып, шушы эремәне атнага бер мәртәбә сипсәң, гөлләр, яңгыр явып үткәннән соң табигать яшәргәндәй яшәреп, матурланып китә. Бөтенләй хәлсезләнгән гөлләрне дә яшәртеп җибәрә. Әлеге катнашма гөлләрнең тамырларын ныгыта, черүдән саклый. Ләкин перекисьле суны чәчәкләренә тидермәскә киңәш ителә. Кыскасы, эремә гөлләргә гүя бәлзәм сиккәндәй тәэсир итә: алар тизрәк чәчәк ата, чәчкәләре озаграк тора.

Тагын шунысы бар: водород перекисе берничә ел буе кучерелмәгән гөлләрнең туфрагын кислород белән баета. Моннан тыш туфракта бактерияләр, гөмбәчекләрне булдырмый.

Водород перекисен яз көне яшелчә үсентеләренә, җәен – теплицадагы үсемлекләргә сибү дә бик файдалы.

Игътибар! Перекисьле суны сибәр алдыннан гөлгә бераз гына чиста су сибеп алырга кирәк.

ТАШЛАМАЛЫ ТАМАША

ЯҢА ЕЛ АЛДЫ ТАШЛАМАЛАРЫНА НИЧЕК АЛДАНМАСКА?

pixabay.com

Кирәк-яракны телефон яки компьютер төймәсенә басып кына сатып алырга күнегүчеләр көннән-көн арта. Менә хәзер шундыйлар өчен «кызу чор» башлана. Яңа елга күп калмый, шуңа интернет-кибетләр «кара җомга», «кибердүшәмбе» кебек акцияләр ясап, халыкны ничек тә күбрәк җәлеп итәргә тырыша.

Ташламалы сәүдә – бик әйбәт инде ул. Тик менә сатучыларның вакыт-вакыт зиһеннәребезне чуалтып, аңнарыбызны томалап, уяулыгыбызны җуйдырып, күзләребезне «сукырайтуы» кәефне кыра. Ә мошенникларга шул гына кирәк: алар виртуаль киңлектәге ташламалы тамаша чорында, киресенчә, үткенләшеп арттырып, «кармак»ларын теләсә кая сала башлый.

«Роспотребнадзор» идарәсе җитәкчесе урынбасары Марина Трофимова интернет-кибетләрдә кырыгалдарлар кармагына эләкмәс өчен нәрсәләрне белеп торырга кирәклеген аңлатты.

Белгеч әйтүенчә, бары тик ышанычлы яки таныш-белешләр киңәш иткән сатучы-компания сайтына гына керергә кирәк. Әле анда да компания турында барлык мәгълүматларны (юридик мәгълүматларын, элемтәгә керү өчен белешмәләрен) өйрәнү, сайтның, чыннан да, шушы интернет-кибетнеке булуына инану әйбәт. Сатучының Салым федераль хезмәтендәге реквизитларын барлап алуның да зыяны юк. Боларның барысы да компаниянең бу дөньяда, чыннан да, барлыгына инану өчен кирәк.

Марина Викторовна, акция турында ишетүгә, тегe яки бу әйбергә заказ бирергә ашыкмаска киңәш итә. Беренче чиратта, аның акциягә кадәр күпме бәядән сатылганлыгын, башка сатучыларда күпме торганлыгын белешү әйбәт. Ник дигәндә, ташламалы дигән товарның, ыгы-зыгыдан файдаланып, артыграк бәядән дә сатып җибәрелүе бар икән.

Шунысын да онытмаска: товар ташламалы бәядән сатып алынуга карамастан, кулланучы буларак, хокукларыбыз сакланып кала. Товарның үлчәме, төсе буенча һ.б. ниндидер ризасызлыклар туса, ике атна эчендә аны алыштыра яки сыйфатсыз товар өчен акчабызны кире кайтара алабыз дигән сүз.

Марина ТРОФИМОВА, мошенниклар корбанына әйләнмәс өчен, түбәндәгеләрне истә тотарга киңәш итә.

1 Бәясенә кызыгып, үзегез белмәгән интернет-кибеттән товар сатып алырга уйласагыз, сатып алучыларның фикерләре белән җентекләп танышып чыгыгыз. Ләкин аларны кибет сайтыннан түгел, ә башка урыннардан эзләгез. Сатучы сайтындагы тискәре фикерләрне бик җиңел генә уңайга да үзгәртергә мөмкин.

2 Сайтның адресына күз салыгыз. Интернет-кибет сайтына кергәч, адрес юлы башында «йозак» символы күрсәтелгәнме , «s» хәрефе төшереп калдырылмаганмы («http» түгел, ә «https» булырга тиеш) – шуларга бик тә игътибарлы булыгыз. Болар сайтның мошенникларныкы түгеллеген аңлата. Сайтта мондый саклау билгеләре юк икән, андагы товарга кызыкмагыз.

3 Интернет-кибеттән тегe яки бу әйберне кемнәрнеңдер телефоны яки компьютеры аша сатып ала күрмәгез. Бу максатта бары тик үзегезнең гаджеттан гына файдаланыгыз. Аның лицензияләнгән антивирусы булырга тиеш: тиешсез сайтка кергән очракта, ул сезне кисәтәчәк.

4 Кибетләрнең рәсми мобиль кушымталарыннан файдаланыгыз. Үзегезгә кирәкле кибетләрнең сайтларын браузердагы «закладка»га саклап куегыз. Ә иң әйбәте – телефонга кибетнең рәсми кушымтасын урнаштыру. Болай эшләгәндә, мошенниклар «кармагы»на эләгү куркынычы бөтенләй юкка чыга.

5 Интернет аша товар сатып алу өчен җәмәгать урыннарындагы Wi-Fi челтәреннән файдаланмагыз. Мошенниклар ялган челтәр булдырып, банк картасы мәгълүматларын урларга мөмкин.

6 Сатучыга банк картасы мәгълүматларын электрон почта яки телефон аша җибәрмәгез.

7 Товар сатып алганда, беркайчан да банк картасының пин-кодын кертмәгез.

8 Интернет-кибетләрдән товар сатып алу өчен өстәмә карта булдырыгыз. Мондый карта банк картасына «бәйләнә». Аңа тегe яки бу товар өчен кирәкле күләмдә генә акча күчерелә. Шулай итеп, ул-бу килеп чыкса да, банк картасындагы башка акчагыз «исәнимин» калачак.

9 Интернет-кибет товарына ике авторизацияле түләү системасы (3-D Secure) аша түләргә тырышыгыз (сатып алучыга һәр товар өчен индивидуаль код белән хәбәр җибәрелә).

Белеп тор!

ҖИМЕШЛӘРНЕ «ӨЛГЕРТҮ» СЕРЛӘРЕ

Кибетләр һәм базарлар хөрмә белән тулды. Тик тулышып өлгергәннәрен табу гына кыенрак. Таштай каты хөрмәнең тәме дә юк, авызны да бөрештерә. Шуңа күрә суыткычта тундырып, аннан соң эретеп мәшәкатьләнергә туры килә. Ә бу витаминнары таркалуга, матурлыгы югалуга китерә.

Хөрмәне өйдә өлгертүнең дөрес ысулы мондыйрак. Кара капчыкка салып, янына алма куябыз да бүлмә температурасында тотабыз. Алмадан бүленеп чыккан этилен көньяк җимешенең тулышып өлгерүенә китерәчәк. 1 кило хөрмәгә 2–3 алма кирәк. 3–5 көннән соң хөрмә йомшарып, аңа татлы тәм керәчәк. Алма урынына банан кулланырга да мөмкин.

Яңа ел алдыннан нигәдер ананас, манго кебек экзотик җимешләргә дә күз төшә башлый. Боларын да өйдә өлгертеп җиткерергә була.

Ананасны кәгазьгә төреп, койрыгын аска каратып «утыртабыз» яки элеп куябыз. 4–5 көннән бик тәмле булып өлгерәчәк.

Мангога килсәк, ул бер ай буе ятса да, өлгермәскә, ә череп әрәм генә булырга мөмкин. Өлгертү өчен, кәгазьгә төреп, целлофан капчыкка салабыз, янына 2–3 банан куябыз. Аннан инде җимешләрнең өлгергәнме-юкмы икәнлекләрен вакыт-вакыт караштырып торабыз (гадәттә 7–10 көннән соң өлгерә). Җылыда сакларга киңәш ителә. Суыткычка куйганда, манго беркайчан да өлгермәячәк.

Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

КЫЛГАН ГӨНАҺЛАР БӘГЫРЬНЕ ТАШ ИТӘ

«Бәгырь катты», «каты күңелле» дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Хәзерге заманда кешеләрнең бер-берсенә карата усалланы, битараф булуы ачык сизелә. Адәм баласына әлеге сыйфатлар кайдан килә? Алардан ничек котылырга һәм җанга ничек тынычлык табарга?



Әлеге сорауларга Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис хәзрәт ГЫЙМРАНОВ белән җавап эзләдек.

:: Хәзрәт, динебез бәгырь катылыгын, күңел караңгылыгын ничек аңлата?

– Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Бу сорауларга җавапны адәм баласының ана карынында яралган мизгеленнән үк карарга кирәк. Җан, калеб, бәгырь, күңел кебек төшенчәләр бер-берсенә бик якын. Адәм баласының организмында әллә ничә әгъза, 360 буын бар. Баш мие тәүлегенә 8 миллиардтан артык химик реакция үткәрә. Адәм баласының йөрәге 115 мең мәртәбә кысыла, 10 мең литр кан үткәрә, 23–24 мең мәртәбә сулыйбыз. Бездәге һәр әгъза Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән илаһи физиологик функциясен үти. Аллаһы Тәгалә шулай яраткан, шулай бар иткән аларны. Ана карынында яралгы барлыкка килгәч, 4 айга кадәр бездә җан булмаган. 120 көн үткәч, Аллаһы Тәгалә җан белән фәрештә җибәрә. Фәрештә ана карынындагы яралгыга җан өрә һәм ул тереләп китә. Аллаһы Тәгаләдән бирелгән җан кешене тере итеп йөртә дә инде. Җан чыкса, без – үле, мәет. Җанның функциясе нәрсәдә соң? Аны безгә Аллаһы Тәгалә ни өчен бирә? Ул Коръәни Кәримдә: «Мин җаннарыбызга яхшылык белән яманлыкны аеру сыйфатын бирдем», – ди.

Безнең төп максат – җанны чиста тоту. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Кыямәт көнендә сезгә малларыгыз да, балаларыгыз да ярдәм итмәс, сәламәт калеб кенә коткарыр», – ди. Менә шушы күңел, җан чистарак булган саен яхшырак. Машинаны юдырып чыгаргач, пычракка керәсе килми бит. Адәм баласының җаны чистарак, иманы ныграк булган саен, ул гөнаһларны әйләнеп үтә башлый. Аны алар кызыксындырмый. Җан ул – үзенә күрә антивирус, чик сакчысы. Аның чисталыгы безнең рухи бөеклекне күрсәтә.

:: Алда әйтеп үткән сыйфатларга нинди сәбәпләр китерә?

– Безнең күңелне нәрсә каралта? Моңа, әлбәттә, Коръәнебездә дә, пәйгамбәребез сөннәтләрендә дә аңлатма бар. Иң беренче сәбәп – гөнаһ, аларның барлык төре. Ялган, гайбәт, хәрам ризык, кирәкмәгән нәрсәләргә, гаурәткә карау, дисеңме. Болар барысы да йөрәгебезне каралта. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең «Бәкара» сүрәсенең башында ук: «Аларның йөрәкләренә һәм колакларына мөһер суктык, күзләренә исә пәрдә кордык», – ди. Димәк, Аллаһы Тәгалә йөрәкне каплап куя. Пәйгамбәребез (с.г.в.) үз хәдисендә: «Адәм баласы гөнаһ кылган саен, калебенә бер кара тамчы төшә», – дип искәртә. Бер төште, ике төште... Шартлы рәвештә генә карыйк: уч төбе кадәр йөрәгебезне алып, аны фломастер белән буяп карасак, берничә сәгатьтә буяп бетерерлек бит.

Гөнаһларның нинди булуы да тәэсир ясый. Карагыз сез, нинди ирекле заманда яшибез! Хәзерге вакытта гөнаһ кылу шулкадәр җиңел! Әйтик, Америкада яшәүче кешене өйдән чыкмыйча гына мыскылларга мөмкин. Телефоннан, «Инстаграм»да, «Ватсап»та була бит! Бик күп әшәкелек чәчәбез, кемнәрдер бәгыренә каты кагылабыз дип уйламыйбыз. Ә нәфес «җитте» дигән сүзне белми.

Күпләребез дөньядагы урын, байлык өчен гөнаһ кыла, башларга баса-баса өскә үрмәлибез, зуррак кисәкне эләктереп калырга телибез. Салкын караш, битарафлык менә шулардан – динсезлек, әдәпсезлектән килеп чыга. Дин адәм баласының җанын дәвалый торган бердәнбер алыштыргысыз юл булып тора.

:: Кайгырту сәләтен, мәрхәмәтлелекне ничек кайтарырга соң?

– Коръәни Кәримдә бик хикмәтле аять бар. Анда: «Без Коръәнне тауга иңдергән булсак, тау ишелгән булыр иде», – диелә. Галимнәр моңа берничә аңлатма бирә. Ягъни Коръән белән таш бәгырьләрне дә йомшарту мөмкин. Икенче мәгънәсе: тау күтәрә алмаганны кеше күтәрер. Адәм баласының йөрәге нык, көчле. Бу дөньяда безне акыл иясе итеп мәрхәмәтле була белүебез күрсәтә.

Бу сәләтләрне ничек кайтарырга соң? Иң элек, изгелекләр кылу. Күбрәк Аллаһы Тәгаләне зекер итү. «Йөрәкләрегез Аллаһы Тәгаләне зекер кылудан тынычлык табар», – диелә Коръәнебездә. Коръән уку, әйткәнебезчә, таш йөрәкне дә йомшартырга сәләтле. Кешеләргә ярдәм итү, авыр хәлдә булганнарның хәлен барып күрү, ятимнәрнең башларыннан сыйпау, картлар, балалар йортларына бару – гомумән, булышу. Аллаһы Тәгалә тарафыннан рәхсәт ителгән һәр нәрсә безгә файдага. Ислам диненең биш баганасы турында да онытмаска кирәк. Ул ихтыяр көчен ныгыта.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Каты бәгырьле булу җанга тынычлык таба алмаганнан да киләдер ул. Бу очракта нишләргә?

– Без бик кызыклы заманда яшибез. Кибет киштәләре тулы, фатирлар бар, байлык күп. Беләсезме, нәрсәгә кытлык? Тынычлык, тормышның бәрәкәте юк. Бүген өйнең җылысы юк. Сүз батареяга килә торган җылылык турында бармый, ә гаиләдәгеләрнең үзара мөнәсәбәтләре турында бара. Бер-береңне аңламау бик еш очрый. Байлык була торып та, йортка кайтасы килмәү, бер-беребезне ишетеп тә, аңлый алмавыбыз – имансызлыкның, бәгырь катылыгының, калеб каралуның ачы җимеше. Җанга тиешле ризык бирмәү тынычлык юклыкка китерә. Җан бәргәләнә, мескен. Хәмер дә кабып карый, зина да кылып карый, тегесен дә эшли... Нишләргә дә белми! Җанның ризыгы – зекер, дога, тәсбих, изгелек.

Һәр нәрсәнең дәвалау чарасы бар. Аллаһы Тәгалә безне шулай яраткан. Тән авыртты исә – дәвалыйбыз, тән пычранды исә – юабыз. Җанны җыр-моң белән генә дәвалап булмый ул. Күп даруларның да бит төп сыйфаты – авыртуны басып тору гына. Алар дәваламый. Без дә хәзер шуның белән шөгыльләнәбез. Без кыска вакытлы ләззәт белән бәхет төшенчәләрен бутый башладык бугай.

Кешеләр арасында гадилек бетте. Без барыбыз да «важный». Бер сүз әйтергә ярамый. Рәхәтлектән рәхәт чигә башладык. Шуңа күрә кеше бер-берсен күрми. Авырлык килсә, ничә еллар дошман булып яшәгән туганнар да берләшә. Кайгылар килмичә дә берләшсәк иде.

Гыйбрәт ал!

pixabay.com

ЙӨЗЕНӘ ГЕНӘ КАРАМА

Локман Хәкимнең ике хатыны булган. Берсенең – күзе, икенчесенең аягы зәгыйфь икән. «Син – акыл иясе, ни өчен кимчелекле хатын алдың?» – дигән сорауга: «Хатын-кыз ирдән күркәмлектә, байлыкта, нәселдә – кимрәк, тәкъвалыкта артыграк булса хәерле. Күп вакыт чибәр хатын иргә түгел, ир аңа хезмәт итә, ир хатын колына әйләнә», – дип җавап биргән.

Тарихка күз салсак та, дөньяны тетрәткән падишаһлар чибәр хатыннары аркасында харап булган: Атилла, Александр Македонский һ.б. Төркиянең данлыклы Сөләйман патшасы да хатыны Роксалана алдында көчсез булган.

Акыллы кеше хатынны байлыгына, чибәрлегенә карап түгел, акылына, әдәбенә, тәкъвалыгына карап сайлый.

(«Локман Хәким нәсыйхәтләре» китабыннан)

Өч хәдис

- Туганлык җепләрен өзүче белән дус була күрмә, чөнки Аллаһ андыйларны үз Китабында өч урында каргаган.
- Нәселегезне өйрәнегез, шуның белән туганлык җепләрегезне бәйләрсез. Туганлыкны ныгыту гаиләдә мәхәббәтне булдыра, байлыкны арттыра һәм гомерне озынайта.
- Гыйлем эстәүче гыйлемгә ирешер, гыйлемгә ирешкәч, гөнаһ кылудан куркыр.

Миң дә бер дога

Кием кигәндә укыла торган дога

«Әлхәмдүлилләһил-ләҙи кәсәни һәҙәҫ-ҫәүбә үә разәканиһи мин гайри хәүлин минни үә лә куүәһ».

Мәгънәсе: «Минем көч-куәтемнән тыш, мине ошбу киемгә киендергән вә аның белән мине ризыкландырган Аллаһка барча мактаулар булсын».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ЛӘЙСӘН ГЫЙМАЕВА:

«ТАҢСЫЛУ БЕЛӘН УРТАК ФИКЕРГӘ ТИЗ КИЛӘБЕЗ»

Гаилә – беренче урында, әмма үзең турында да онытмаска кирәк. Өч сылу кыз әнисе, «Сәламәт марафон» проекты авторы, «Инстаграм»да Җиләк Кычытканова, Дивания, Фифа булырак та билгеле Ләйсән Гыймаева әнә шул фикердә. Без аны «Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка чакырып, яңалыкларын белештек.

:: Ни хәл?

– Әйбәт, Аллага шөкер. Яңа ел тапшырулары төшереп мәш киләбез әле. Үзебез дә бәйрәмгә әзерләнә башладык. Яңалыклар әллә ни юк, бар да бер көйгә.

:: Күптән түгел кызыгыз Таңсылу белән «Әйбәт кеше булсаң әгәр үзең» җырын чыгардыгыз. Ул җырның туу тарихы турында сөйләсәгез иде.

– Мин зур мәктәпләр төзүгә каршы. Мәктәп дүрт параллельдән артмаска тиеш. Директор коллективын, укытучыларын, аларның ничек укытканын белми башлый. Укытучы эшенә өйрәнергә кирәк. Сыйныфта 30 бала бит. Аның өчен фәнеңне яхшы белүдән башка, зур энергия, психолог булу да кирәк. Белем бирү ул – кешелек тәҗрибәсен яңа буынга җиткерү. Әгәр мәктәптә укымасаң, маймыл булып каласың. Дөньяда андый тәҗрибә дә бар. Хайваннар янында үскән кешене сөйләшергә өйрәтеп булмый.

:: Мәктәпләрдә укытучылар җитмәүнең сәбәбе нидә?

– Беренчедән, Казанда педагогика вузын ябуда. Икенчедән, фәннәрне татар телендә өйрәтүче укытучылар әзерләнмәүдә. Бу бит – җинаять. Бакчада татарча белгән тәрбиячеләр бик аз. Казан педагогия көллияте билингваль тәрбиячеләр әзерләми. Арчада бер төркем ачканнар. Татарстанда 2 миллион татар яши, 100 мең татар баласы бакчада тәрбияләнә дигән сүз. Аннан бакча татарча тәрбияләми, дип кычкыралар. Татар телен белгән тәрбиячеләрсез ничек булсын инде ул?

:: Милли мәгарифтә үзгәрешләр сизеләме?

– Полилингваль мәктәпләр барлыкка килә башлады. Үзгәреш шунда. Башка юл юк. Мәктәпләрдә хәзер туган телне әти-әниләр сайлый. Авылда да әти-әниләр балаларын татарча укытырга куркалар. Янәсе, ул-кызлары вузга керә алмаячак, авылда калып, харап булачак. Шуңа күрә 1 нче сыйныфтан башлап, өч телдә укыта башларга кирәк. Хәзер авылда да кош, үлән исемнәренең татарчасын белмиләр бит.

Әңгәмәдәш – Сәрия МИФТАХОВА

ДАРУ ЭЗЛӘП... БАГУЧЫГА?!

РОССИЯДӘ КОРОНАВИРУСТАН КҮРӘЗӘЧЕДӘ «ДӘВАЛАНУЧЫ»ЛАР САНЫ АРТКАН

Коронавирус дигән зәхмәт табибларның гына түгел, могҗиза белән эш итүче им-томчы, күрәзәчеләрнең дә эшен арттырган. Соңгы арада Россиядә багучыга йөрүчеләр саны артып киткән. Ник дигәндә, бу белгечләрнең күбесе хәзер коронавирустан дәваларга, чиргә каршы саклагыч куярга вәгъдә итә башлаган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Багучы да – интернетта

Мәскәүдә яшәүче 42 яшьлек Ирина исемле хатын күптән түгел бер багучы өстеннән гариза язган. Күрәзәче аңа коронавирустан саклагыч куярга вәгъдә иткән. Чәч төпләренә көл сибү, шифалы су эчерү, ниндидер сәер сүзләр кабатлаудан гыйбарәт булган алты сеанс өчен Ирина ярты миллион сумга якын акчасын чыгарып салган. Ковидтан бер-бер артлы әнисен, апасын югалткан хатын аны йоктырудан шул дәрәҗәдә курыккан, күрәсең. Әмма багучыда сеанслар тәмамланып, бер атна узгач, коронавирус белән хастаханәгә эләккән. Шуннан күзләре «ачылган» хатын алдануы хакында полициягә хәбәр иткән.

Хәтерләсәгез, әле күптән түгел генә хокук сакчылары Уфадагы бер им-томчыны тикшергән иде. Лада исемле хатын ковидка каршы махсус пистолет ярдәмендә, кешегә кычытканнан ясалган пулялар атып, «блок» куеп йөргән. Бу ярдәме өчен 6 мең сум акча сораган ул. Соңгы арада кибет киштәләрендә «КоронаСтоп» дип аталган, үләннәрдән торган бәлзәм дә күренә башлады.

Курыкканга куш күренә дигәндәй, атлаган саен ковид дигән зәхмәттән өркеп яшәгән көннәрдә «коронавирустан коткарам», «чирдән сакланырга ярдәм итәм» ише игъланнар әллә каян күзгә ташлана икән ул. Интернетта «коронавирустан коткарам» дип язган дистәләрчә багучының игъланы чыкты. Белгечләр тырыша-тырыша коронавируска каршы дару эзләгәндә, багучылар инде бу чирне җиңү ысулларын әллә кайчан тапкан икән ләбаса.

Игъланнардан аңлашылганча, берәүләр ковидтан шифалы төнәтмә ясап бирергә вәгъдә итсә, икенчеләре фото буенча яки телефон аша гына кешене чирдән дәваларга, ковидка каршы саклагыч куярга вәгъдә итә. Артык вакланып тормыйча, игъланда турыдан-туры үзенең «Инстаграм», «ТикТок»тагы сәхифәсенә сылтама куючылар да бар. Күрәзәчеләрнең онлайн рәвештә эшләүгә күчүенә гаҗәпләнерлек түгел анысы. Чир котырган чорда болай эшләү күркынычсызрак бит. Ул-бу була калса, интернет аша эш итүчеләрне җаваплылыкка тарту кыен икәнлеге дә көн кебек ачык. «ТикТок»та #гадалка хештегы белән урнаштырылган роликлар бүген 600 меңнән артык карау җыя. Кайбер онлайн багучыларның язылучылары 300 меңгә кадәр җитә.

ДНКны да «үзгәртә»

Игъланнарны җентекләп өйрәнеп чыккач, берничә күрәзәчегә үзебез дә ярдәм сорап мөрәҗәгать итеп карарга булдык. Иң беренче игълан буенча шалтыраткач, трубканы корырак кына тавышлы ханым алды. Коронавируска каршы саклагыч куйдырырга теләвемне әйткәч, исемемне, әтиемнең исемен, яшемне сорады да, «Ватсап»ка фотомны җибәрергә кушты. Организмым ни дәрәҗәдә көчле, ковидка каршы саклагыч куярга кирәкме-юкмы – башта шуны тикшерәсе икән, янәсе. Күп тә үтмәде, шул ук «Ватсап» аша кире үзе шалтыратты. Ни гаҗәп, инде күп еллардан бирле борчыган бер чиремне күргән. Нәселдәге авыруларны да атады. Яшермим, шушы сүзләрдән соң бераз ышаныч ук барлыкка килә башлады моңа.

Шунда ук: «Сезнең кебек фәлән авыруы булган кешеләрне ковид ешрак ега. Шуңа күрә һичшиксез саклагыч куярга кирәк», – дип куркытып та куйды. Саклагыч дигәнең бер тапкырдан гына куелмый икән. Моның өчен 4–5 сеанс кирәк булачак, янәсе. Бер сеанс – 500 сум. Сеанс көнне бу миңа видеодан шалтыратып, минем күз алдында каршындагы фотома нәрсәләрдер укыячак, сибәчәк икән. Мин исә шул вакытта ул өйрәтеп куйган сүзләрне кабатлап торырга тиеш булам. Шул рәвешле юклы-барлы бер атнадан миңа ковид дигәнең бер грамм да куркыныч булмаячак, янәсе. Маскасы да, прививкасы да кирәкми. Саклагыч куелган бит! Уйлап бетергәч, элемтәгә керергә вәгъдә биреп, саубуллаштым.

«Инстаграм»дагы сторизларның берсендә «Ярты сәгать эчендә коронавируска каршы торырга өйрәнәбез» дигән игълан күзгә чалынды. Анастасия исемле багучының аккаунтында узачак булган туры эфирның темасы икән бу. Күрсәтелгән вакыт җиткәч, туры эфирны карый башладым. Коронавирус белән магиянең бәйләнеше турында ярты сәгать буш сүз сөйләгәч, туры эфирда катнашкан һәркемгә коронавирустан индивидуаль саклагыч куярга тәкъдим итте бу. 990 сум акчаңны түләсәң, күрәзәче синең белән элемтәгә керә дә, чиргә каршы торырлык итеп, онлайн рәвештә ДНКны «үзгәртә» икән. Туры эфирны караган 1,5 мең кеше арасында бу мөмкинлектән файдаланып калырга теләүчеләр шактый булып чыкты.

Күпләргә Казанның Фучик урамында кабул итүче буларак билгеле Марина исемле багучы да онлайн рәвештә эшләүгә күчкән булып чыкты. Ул гына да түгел, ковидтан дәвалый башлаган. «Гаиләләре белән ярдәм сорап килүчеләр бар. Ун көн дигәндә аякка бастырам», – дип шаккатырды Марина. Нинди алымнар ярдәмендә чирдән дәвалавын гына сер итеп калдырды. Һәркемгә индивидуаль ысул куллануын гына әздереп әйтә алды. Бу ярдәме өчен, коронавирусның ни дәрәҗәдә җитди булуына карап, 1–2 мең сум акча ала икән. Гаиләләре белән килгән кешеләргә ташлама ясыйм, ди.

Курку йөртә

Яшерен-батырын түгел, багучы бусагасын, гадәттә, хатын-кызлар таптый. Соңгы тапкыр уздырылган илкүләм сораштыруда гүзәл затларның 30 проценты даими рәвештә багучыларга йөрүен әйткән. Күрәзәчеләргә ковидтан коткаруын сорап мөрәҗәгать итүчеләрнең дә күпчелеген хатын-кызлар тәшкил итә икән. Һәрхәлдә, без элемтәгә кергән багучыларның күбесе шулай дип белдерде. Бу күренеш нәрсә белән аңлатыла соң? «Жасмин» психология үзәге белгече Наилә Бәширова сүзләренә караганда, бу хатын-кызның табигате белән бәйле. «Ир-ат табигате буенча – табучы. Хатын-кыз исә бу дөньяга тормыш бүләк итә һәм гомер буе шушы тормышны саклау, яклау ягын кайгырта. Шуңа күрә гүзәл затларның авыр вакытларда им-томчы, күрәзәчеләр янында могҗиза эзләвенә аптырый торган түгел», – ди психолог.

Белгеч сүзләренә караганда, багучы ярдәмендә коронавируска каршы торырга тырышучыларның күбәеп китүе җәмгыятьтәге киеренкелек көчәю белән дә бәйле. «Баштарак коронавирус турында бөтен белгечләр дә бер үк сүзне сөйли иде. Әмма соңгы арада ковидка каршы гылышлы бер-берсенә шактый каршы килгән мәгълүматлар пәйда булды. Кеше аларның кайсына ышанырга белми. Мондый билгесезлек, курку хөкем сөргән шартларда кеше, гадәттә, күрәзәче, багучыларга йөри башлый да инде. Күрәзәчегә мөрәҗәгать иткән кеше еш кына үз тормышы өчен җаваплылыкны башка кеше җилкәсенә аударырга тырыша», – ди Наилә Бәширова.

Табиб-терапевт, медицина фәннәре кандидаты Равия Сальманова бу күренешнең тагын бер куркыныч ягын атый.

– Багучы юлын таптаган кеше иллюзиядә яши. Чынлыкта коронавируска каршы көрәштә бернинди магия дә, күрәзәче дә булыша алмый. Чирне медицина алымнары белән җиңү дә таманга гына килә әле. Юк-бар сүзгә ышанып йөргән кеше, миңа берни дә янамый, дип тынычланып, битлектән йөрү, дистанция саклау, кулларны-битләрне чиста йөртү кебек гади генә саклану кагыйдәләрен дә үтәмәскә мөмкин. Үпкәләрендә үзгәрешләр башланган булса, багучыда «дәваланып» йөргән кеше алтынга тиң вакытын югалтачак. Ник дигәндә, үпкәләр бик тиз зарарлана. Кеше үз хәленең ни дәрәҗәдә җитди икәнен аңышканда бик соң булуы мөмкин, – ди белгеч. Ал күзлек киеп, чирне җиңеп булмый шул. Коронавирусны бигрәк тә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Фикер

Артур ГАЛӘВЕТДИНОВ, юрист:

– Әлегә Россиядә күрәзәчеләрнең эшчәнлеген контрольдә тотучы махсус закон юк. Ләкин бу кырыгалдарларны берничек тә хөкемгә тартып булмый дигән сүз түгел. Аларны «Кулланучылар хокукларын яклау» законы, «Вак урлау», «Мошенниклык» маддәләре буенча җаваплылыкка тартырга мөмкин. Алар буенча җәза берничә мең сум штрафтан башлап 10 елга иректән мәхрүм ителүгә кадәр үк җитәргә мөмкин. Багучыны җаваплылыкка тарту җайлырак булсын өчен, аның белән булган барлык сөйләшүләрне диктофонга яздырып барырга кирәк. Полициягә мөрәҗәгать иткәндә, дәлил буларак, багучы белән язышуыгызны раслаган скриншотны, аның социаль челтәрдәге аккаунтын, телефон номерын, аңа онлайн рәвештә акча күчергән булсагыз, чегын да күрсәтә аласыз.

Сан

Россия халкы ел саен багучыларга 30 миллиард сум акча сарыф итә икән. Россия Фәннәр академиясенең социология институты мәгълүматларына караганда, ил халкының 62 проценты им-томчы, багучыларның эшчәнлеген хуплый.

АНА

Гәрчә инде 103 яшьтә булса да, Газинур Гафиятуллинның хатыны Гыйльмурый әбинең үлеме минем өчен көтелмәгән хәл булды. Советлар Союзы Геройларының бүген исән-сау бердәнбер хатыны иде ул. Кызлары, улы Әнвәр аша бик еш булмаса да, хәлен белешкәләп тордык. Гыйльмурый әбинең үлемен кызы Римма телефоннан хәбәр итте. «Өебез бушап калды, әни җитми», – дип язган иде ул. Үзенә шалтыраттым, сүзен әйтә алмый, сулкылдый-сулкылдый елый. «Урыны оҗмахта булсын...» – диюдән ары уза алмадым.

Газинур сугышка киткәндә, ана карынында калган улы Әнвәргә дә шалтыраттым. Ул да аптырашта иде. «Менә шулай килеп чыкты инде», – диде дә, бүтән бер сүз дә әйтә алмады. Бу юлларны үзем дә аптырабрак язам. Үләргә тиеш түгел иде кебек Гыйльмурый әби. Ул балалары өчен дә, без – танышлары өчен дә «Ана» дигән бөек затның символы, җыелма образы кебек иде. Инде менә тере образ юк, хәтер генә калды.

Хәтер димәктән, телефонга яман хәбәр килгәндә, мин ике яшь егет белән машина тирәсендә маташа идем. Татарлар иде алар. «Егетләр, Газинур Гафиятуллинның хатыны үлгән бит», – дидем. Миңа аптырап карадылар да: «Кем соң ул?» – дип сорадылар. Мин аларга бернинди дә дәгъва белдермим, үпкәләмим, чөнки алар – бүгенге җәмгыять, бүгенге тәрбия җимешләре. Ә диңгез баштан болгана, совет чорына, шул чорның шәхесләренә, гафу итегез, төкереп карау гадәти хәлгә әйләнде. Шул ук вакытта яшь буында патриотлык хисләре тәрбияләү кирәклеге турында сөйлибез. Тәрбия ул тарихка нигезләнергә, шәхесләр үрнәгендә алып барылырга тиеш. Коры сүз кеше күңеленә үтеп керә алмый.

Дошман пулеметын күкрәге белән каплар өчен дзотка кадәр араны – яшәү белән үлем арасын йөгереп үтәргә үзендә көч тапкан Газинурның кем икәнен белмәс дәрәҗәгә җиттек. Гыйльмурый әби үзе дә бер легенда иде.

Аның янына очрашуга барыр алдыннан бер сүз ишеттем: янәсе, Гыйльмурый Газинурга хыянәт иткән, икенче иргә кияүгә чыккан.

Сугыш һәм сугыштан соңгы елларны күз алдына китереп карыйк. Илдә ачлык, күпме ятим, күпме тол хатын. Ә Гыйльмурый үзенең өч баласы белән Азнакайның Исрафил атлы кешесенә кияүгә чыга. Гыйльмурый әле әтисенең туганы Кашафетдинның ятим калган ике баласын да үзенә ала. Моңа блокададагы Ленинградтан килгән ике ятимне дә өстәргә кирәк. Хәлләрәк кешеләрнең аларны аласы килми, ә ачлы-туклы яшәгән Гыйльмурый һәм Исрафил үзләренә сыендыралар. Бу очракта хыянәт турында сүз дә булырга тиеш түгел. Гыйльмурый белән Исрафил яшәү, тормыш дәвам итсен өчен гаилә корганнар. Гыйльмурый Исрафилдан да биш бала таба. Димәк, үзләренеке һәм тәрбиягә алганнарны кушып, 12 бала тәрбияләп үстергән. Бүген үз балаларын ташлап китүче аналар да очрый, кая кеше баласын карау ди ул!

Рухи кыйммәтләр әнә шулай үзгәрде. Тагын бер кызык, дөресрәге, кызганыч хәл: Гыйльмурый әби белән очрашуга барырга җыенуымны әйткәч: «Газинур Гафиятуллинның хатыны исәнмени?» – дип гаҗәпләнүчеләр дә табылды. Алар арасында каләм ияләре дә юк түгел иде. Үземне дә әллә кемгә куясым килми, Гыйльмурый әбинең исән-сау булуы, кызы Римма белән кияве Мөдәррис гаиләсендә яшәве турында ул чакта «Таттелеком» элемтә оешмасында эшләгән Рөстәм Гомәров сөйләгән иде. Сөйләү генә түгел, үз машинасына утыртып алып та барды ул мине Бөгелмәгә, Газинур Гафиятуллинның Сугышлы авылындагы музеен да бергәләп карап чыктык.

Гыйльмурый әби янына беренче баруында Рөстәм Гомәров ул вакытта «Таттелеком»ны җитәкләгән Лотфулла Шәфигуллиннан күчтәнәчләр дә тапшырган. Аның күчтәнәчләре моның белән генә тәмамланмады әле. Тиешле урыннарга мөрәҗәгать итеп, Гыйльмурый әбине «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләүләренә иреште. Ә, асылда, рәсми танылмаса да, герой ана ул Гыйльмурый әби. Бөтен гомерен балаларына багышлаган, 70 яше тулганчы эшләгән, ягъни илгә хезмәт иткән. 103 яшьлек бу ана әле зур гаиләне: бала, оныконыкчыкларын санап, 50гә якын кешедән торган нәселне таратмыйча тотып тора иде.

Хәлемнән килсә, мин Бөгелмәдә, йә Лениногорскида Гыйльмурый әби истәлегенә һәйкәл куйдырыр идем. Үткән-сүткән кеше аңа карап: «Кара әле, шундый аналар да булган!» – дип сокланыр һәм уйга калыр иде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ЭЗЛИМ СИНЕ, БАБАЕМ!

СУФИЯ ӘБИ ДҮРТ ЕЛ ЭЛЕК ЮГАЛГАН ИРЕН ҺАМАН ДА КӨТӘ

Таякка таянган, кулына төенчек күтәргән әби, җилҗил килеп, олы юлдан атлый. Туктатып, хәлен белешергә булдык. Адәм баласын юлга нәрсә чыгара? Елмаеп кына сөйләшсә дә, күңелендә шушы төенчек кадәрле борчуы бар булып чыкты. Дүрт ел элек ире – Тәлгате юкка чыккан икән. «Бабаемны табарга булышыгыз әле!» – дип үтенде ул.

81 яшьлек Суфия әби Арча районының Наратлык авылыннан булып чыкты. Акчишмә авылыннан кайтып барышы икән. «Адашып йөрмим мин, кызым. Бер йөргән юлдан җайлап кына йөрим. Күрше авылга кибеткә барган идем», – дип сөйли башлады ул. Җәяү йөрүгә исе китми аның. Азмы-күпме тән языла, саф һава сулыйм, хәрәкәтләнеп торырга кирәк, ди. Хәзергә анда башка кайгы әле. 55 ел гомер иткән ире юкка чыккан. Күпме генә эзләсәләр дә, таба алмаганнар.

Наратлык – табигать кочагына сыенган бик матур, әмма кечкенә авыл. Элек аны Арча урманчылыгы дип йөрткәннәр. Монда 33 хуҗалыкта 83 кеше яши. Шулар арасыннан 7се – пенсия яшендә. Суфия апа авылда кибетче булып эшләгән.

– Бабаем Тәлгатькә – 82 яшь. 20 майда төнге 2 нче ярты тирәсендә өйдән чыгып китте ул. Чыгып йөрмәсен дип, капкаларны да бикләп куйган идем югыйсә. Бакча артындагы сарай ишеген ачып чыгып китте. Якында гына – урман. 55 ел урманчы ярдәмчесе булып эшләде. «Россиянең атказанган урманчысы» дигән исеме дә бар. Күңеле урманга тарткан, күрәсең. Егылырсың, йөрмә, дип әйткәләгәндә: «Мин бит ул урманда күзне йомып та йөри алам, борчылма», – дия иде. Зиһене чуала торган гадәте бар. Төнлә чыгып, өйне таба алмыйча йөргәләгәне дә булды. Таныш-белешләр өйгә китереп тә куйгалады. Авыл халкы, укучылар да эзләп карады. Ни үзе, ни эзе юк, – дип искә ала Суфия әби. – Начар яшәмәдек. Тормыш булгач, төрле хәлләр була. Сагындыра бик. Бергәләп чөкердәшеп чәйләр эчә, яшьлекләрне искә төшерә идек. Парлы яшәү бик рәхәт иде. Ялгызлык бик авыр, билгесезлектә яшәү тагын да үзәкне өзә. Тәрәзәдән карап, юксынмаган көнем юк. Болай булса, үзеңнең дә сатушуың бар, билләһи. Радио тыңлап, газеталар укып, үземне юатырга тырышам. Аптырап, күрәзәчегә дә барган идек. «Өегездән ерак түгел урында йөргәе, башы авыртып егылган, өстен үләннәр каплаган инде», – диде. Күрәзәче сүзенә дә ышанып яшәп булмый. Күңел кайтыр әле дип өметләнә. Үзе кайтмаса, мәетен табып, дога кылып, җирләр идек.

Суфия апа үзен, Тула татары, ди. Әти-әнисе – Арча, Балтач якларыннан. Өйләнешкәч, Тулага киткәннәр. Суфия шунда туган.

– Әти сугышка киткәндә әнигә: «Мин сине ничек эзләп табармын, авылга кайт», – дип, Арча якларына кайтарып җибәргән. Сугыштан кайткач, әти Акчишмәдә колхоз рәисе булып эшләде. Гаиләдә дүртәү идек. Ике туганыбыз сабый вакытта ук вафат булды. Төпчегебез Гомәр Дмитровград шәһәрендә яшәде, күптән түгел ул да бакыйлыкка күчте. Хәзер туганнарым калмады. Ике улым бар. Берсе, яшәргә безгә кил, дип чакыра. Тик өйне ташлап китәсе килми шул.

– Тәлгать бабай суга төшеп югалган кебек булды. Саташып та йөргәләде. Өйдә тик кенә утырып тора алмый иде. Акчишмә юлларында күргәләгәндә, өенә илтеп куя идем. Сабантуйларында атказанган урманчы, авылның хөрмәтле кешесе дип, котлап, бүләген дә биргәләдек. Игътибарсыз калмасын дип тырыштык. Күңеле була иде, – ди Арча районының Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Фәһим Фәйзуллин. – Югалуы бик сәер булды. Яшьләрне җыеп, авыл, урман эчләреннән дә эзләдек. Наратлык авылы урман эчендә урнашкан. Әби шикләнгән бар җирне айкадык. Урман кырыендагы чүплекләр, иңкүлекләр... Коткаручылар этләр белән килгән иде. Табылмагач, хәбәрсез югалучылар исемлегенә кертделәр. Алар киткәч тә, эзләүдән туктамадык. Хәзер дә чүплекләр эттерәбез, полосалар чистартабыз, юл кырыйларын чабабыз. Шул вакытта Тәлгать абый килеп чыгар кебек тоела. Юлда начар кешеләр очрамадымы икән, дип тә уйлыйсың. Җепнең очы табылмагач, Суфия апа якындагы, ерактагы күрәзәчеләргә дә йөргәләде. Багучылар, акча түләсәң, теләсә ничек юата белә. «Ник йөрисез?» – дип тә әйтеп булмый, кайтып сөйләгәнен тыңлап торабыз. Күңелендәгесен бушаткач, аңа җиңел була.

Әгәр хәбәрсез югалган Тәлгать абый Гыйльметдинов турында ишетүчеләр булса, редакциягә яки Арча районының Наратлык авылына хәбәр итүегезне сорыйбыз.

Сәрия МИФТАХОВА

СУФИЯ ӘБИ БЕЛӘН ОЧРАШУНЫҢ ВИДЕОСЫ

РАЯЗ ФАСЫЙХОВ:

«МИН ҖЫРНЫ ТҮГЕЛ, ҖЫР МИНЕ ТАНЫТТЫ»

Репертуарына талымлы, сәнгатькә миссия дип караган җырчылар, кызганыч, бик аз. Шундыйларның берсе – Татарстанның атказанган артисты Раяз ФАСЫЙХОВ. Сәхнәдә күренмәве, сольный концертларының булмавының сәбәбе нәрсәдә? Тамашачы санын арттыру өчен аңа яраклашу дөресме? Шушы һәм эстрадага кагылышлы башка сорауларга ачыклык керттек. Әңгәмәдә тормышындагы табу-югалтулар турында да сөйләде.

:: Раяз, соңгы арада сәхнәдә сирәгрәк күренәсез. Моның нindидер җитди сәбәпләре бармы?
– Әтидә начар авыру ачыклангач һәм тереләтүгә өметнең булмавын белгәч, ничектер дөнья җимерелгән кебек булды. Ул бит – мине кечкенәдән җитәкләп диярлек сәхнәгә алып чыккан кеше. «Попутка» машиналарда концертларга, бәйгеләргә бара идек. Әтинең бер кулында – чемодан белән гармуны, икенчесендә минем костюм... Ул – миңа ышанган, миңа бөтен көчен салган иң кадерле кеше. Баштарак коронавирус чирен йоктырып, үпкәләренең 80 проценты зарарланды. Бик борчулы вакыт булды анысы да. Хатыным Люциянең дә әтисенә инсульт булып, урын өстендә калды. Люция сабый бала карагандай аны тәрбияләде. Август аенда аның да гомере өзелде. Шуннан соң минем әти... Менә шундый кайгылар кичердек. Гомумән, бу ике ел, пандемия ил өчен сынау булды. Сәхнәгә чыгу, концертлар да чикләнде. Төрле проектларда катнашырга тырышсам да, сольный концертлар турында уйлыйсым килмәде. Әтине югалтуны бик авыр кичердем. Мин әле дә аның мәрхүм булуына ышанмыйм. Авылда әни белән яшиләрдер кебек. Тиздән кырыгы була, вакыт узган саен сагыш тирәнәя генә.

:: Сезнең һәр җырыгыз, чыгышыгыз, клипларыгыз уйланган, затлы һәм чыгымлы. Әмма халыкка затлы чыгыштан бигрәк, шоу, җиңел җырлар кирәк кебек. Бу күренеш кәефне төшерәме?
– Беркайчан да халыкка ярарга тырышып иҗат итмәдем. Башта нинди юл сайланган – шуны дәвам итәм. Үз тамашачым бар. Көчләп яраттырып булмый бит, ошатканы тыңлый, ошатмаганы юк. Әти кечкенәдән мәгънәле җырларны сайлап җырлаттыра иде. Шулай тәрбияләде. 2001 елны безнең иске мунчада «Кыр казлары» җырын уйнап күрсәтте дә: «Җырчы булып китсәң, шушы җырны чыгарырсың әле», – диде. 2006 елны мин ул җырны түгел, ул җыр мине сәхнәгә чыгарды, танытты. Мәхәббәт турында җырларны да бик авардан сайлыйм. Аның сүзләре дә, музыкасы да минем күңелгә ятышлы булырга тиеш. Шуннан соң гына аңа алынам.

Клипларны төшерүгә дә җентекләп әзерләнәбез. Ун елдан соң караганда да оялмаслык булсын дигән максат куеп эшлим. Бигрәк мәгънәсез, очсыз, тозсыз төшергәнбез икән, дип әйтерлек булмасын. Килечәк кешеләре, менә бит эшләргә тырышканнар, кызык алымнар кулланганнар, дип әйтерлек булсын. Шуңа күрә җырга карап тарихы языла, актерлары сайлана, һәр мизгеле уйланыла. Ә мондый эш чыгымлы була.

Һәр сәнгать әсәре кебек, ул башта синең үзеңә ошарга тиеш. Әгәр үзеңә ошамый икән, ул беркемгә дә ошамаячак. Безнең иҗат шундый. Ә инде тамашачы кемнедер күбрәк ошата икән, аның өчен кәеф кырылмый. Чөнки үз эшемне яратып эшлим. Яраткан эшнең барыбер нәтиҗәсе булачак.

:: Затлы дигәннән, бер җырның, клипның уртача бәясе күпме?
– Клипларның бәяләре төрле. Монда теләсә нинди сумма атарга була. Музыкаль каналларны ачып чагыштыру мөмкинлеге һәркемдә бар. Агачлар арасында җырлап йөреп, шуны телефонга төшереп, монтажлап бирep тә була. Акча түләсәң, андый иҗатны да эфирда әйләндерәчәкләр. Махсус кинокамераларны арендага алып, утлар куеп, массовкалар оештырып, махсус эффектлар кулланып та эшләп була. Кайсы эшнең чыгымлырак, кайсының арзанрак икәнен аңлаган кеше аңлый инде. Минем өчен һәрбер клип – аерым бер сәнгать әсәре.

:: Һәрвакыт «тере» тавышка җырлап буламы?
– Һәрвакыт «тере» тавышка җырлап була, әгәр тавыш һәм техник мөмкинлекләр булса. Күп кенә телевизион концертларда фонограмма кулланырга туры килә, аның таләбе шундый. Концертларда тамашачы алдында, әлбәттә, «тере» тавышка җырлыйбыз.

:: «Үзгәреш җиле» фестиваленә караш бер төрле түгел. Ә шулай да, җырчыга ул нәрсә бирә? Тукталып калса, җырчы нәрсәне югалтачак?
– Татар телендә һәм татар сәнгатенә багышланган һәрбер чараны – фестивальме ул, конкурсмы – һәрвакыт хуплаячакмын, чөнки ул барыбер безгә хезмәт итә. Дөрес, һәр яңа башлангыч тәнкыйтькә дучар була. «Үзгәреш җиле»нә килгәндә, ул миңа ошады. Анда эшләп алдым, профессиональ җырчы һәм музыкант буларак, дәрәҗәле музыкантлар белән эшләү кызык булды. Кайбер ягын хуплыйм, кайбер ягын хуплап бетермим. Бәхәсләшкән чаклар да булды. Дәлилләр китереп аңлаткач, фикерне кабул итәләр иде. Мәсәлән, Илһам абый Шакиров җырлаган «Чулпан йолдыз» җырын үзем ничек күзаллыйм, шулай башкардым. Дөрес, фестивальдә чүбе дә күп булды. Урман кискәндә дә пычкы чүбе күп була, бу – табигый нәрсә, акрынлап «Үзгәреш җиле» дә чистарыр, сыйфаты яхшырыр әле. Мюзикларын бик ошаттым. «Алтын Казан» шулкадәр сыйфатлы, составы да көчле, быел да тыңларга исәп тотам. Күбрәк булсын андый проектлар, фикер алышуга сәбәпче булсыннар. Һәрбер фикер үсешкә китерә ләбаса. Үземнең дә проектлар бар. Еллар әйбәтләнеп китсә, гамәлгә ашар, Алла боерса.

> Кайбер җырларга кагылырга ярамый, диләр. Нишләп ярамасын ди инде?! Нинди стиль бар, барысын да җырлап карарга кирәк. Җыр ул – җырлар өчен.

Блиц-сораштыру

– Мөмкинлек булса, тормышта нәрсәне үзгәртер идегез?
– Бернәрсәне дә үзгәртмәс идем. Авырлыгы да, шатлыгы да, юлда очраган кешеләр дә – сабак.
– Хәзерге мизгелдә күңелгә килгән җыр исеме?
– Көн саен күңелдә берәр җыр «йөри». Мин аны үзем «җыр-паразит» дип йөртәм. Кайтып, кулга баян алып, уйнап җырламыйча, тынгылыкта калдырмый ул. Бер көнне керәшен такмакларын уйнадым, бүген Зөлфәт Хәкимнең «Сине югалтсам» җыры тынгысызлый.
– Сезнең фикерегезчә, эстрадада иң уңышлы проект нинди иде?
– «Татар җыры», «Йолдызлар фабрикасы», «Үзгәреш җиле».
– Тормыш девизыгыз нинди?
– Нинди генә хәлдә дә оптимист булудан туктамаска.
– Казан ул – (җөмләне дәвам итәргә)...
– «опасный» шәһәр. Ул сине канат куеп очырырга да, бәреп төшерергә дә мөмкин. Казан ул – серле, үзенчәлекле дөнья. Арчада укыганда, Казанга кунакка килә идем дә, шушында яшисе, «кеше» буласы иде, дип хыяллана идем. Бирегә күченгәнгә инде 18 елга якын. Акрынлап хыяллар тормышка аша. Әмма никадәр генә яратсам да, Казан барыбер арыта. Ял итәр өчен авыл, табигать кирәк.

«Үзгәреш җиле» туктаса, башкасы булачак. Туктар дип ис-акыл китми. Чөнки бер генә нәрсә дә мәңгелек түгел. Ләкин ул татар җырларын дөнья стиленә туры килерлек аранжировкалар белән эшләп булганын күрсәтте, яхшы үрнәкләр булды.

:: Профессиональ җырчыга дәүләт ярдәме кирәкме?
– Профессиональ җырчы үзенә халык җырларын, классик сәнгатьне үстерү миссиясен алган булса һәм катлаулы хәлдә калса, әлбәттә, аңа дәүләт ярдәме кирәк. Элек бит җырчыларга фатирлар бирелгән, радиода язылган өчен алар түгел, киресенчә, аларга акча түләнгән. Дөрес, һәр чорның – үз авырлыклары. Ләкин ротация бәяләренә субсидия яки ташламалар булса, бер дә комачау итмәс иде. Дәүләт ярдәме теләсә кайсы җырчыга түгел, билгеле бер миссия алып барганнарга, тәрбия юнәлешендә эшләүчеләргә булсын иде.

:: Тормышыгызда иң зур терәк кем?
– Тормышымда иң зур терәгем – хатыным Люция һәм балаларым. Шөкер, юлымда гел яхшы кешеләр генә очрап торды. Терәк булырдай дусларым да бар. Ул яктан мин бәхетле. Гаиләм – ныклы тылым.

:: Сүз уңаеннан, кызыгыз Венера исемле икән. Остазыгыз Винера Ганиева хөрмәтенә кушылмагандыр бит?
– Кызыма Гөлсинә исеме кушмакчы идем. Үскәч, Гуляга әйләндереп бетерерләр дип әйттеләр дә, ниятемнән кире кайттым. Үзгәрми торган исем уйлый башладык. Чынлап та, Винера Әхәт кызы Ганиевада укыган вакытлар. Ә ул – минем тормышымда бик зур роль уйнаган кеше. Ә бит Венера Раяз кызы матур яңгырый дип уйлаштык та, хатыным белән шушы исемгә тукталдык. Улым исә рамазан аенда туды, аңа исем эзләп баш ватмадык, Рамазан дип куштык. Аллаһы Тәгалә үзе үк исемен җибәрде.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы. Башы 4, 12 ноябрь саннарында

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ТАМГА

(хикәя)

Ир бармакларын чәченә батырды. Сызлый баш, сызлый! Әллә үзе, бары тик үзе генә гаепле микән? Адәм баласы, гадәттә, хаталарның җеп очын бүтәннәрдән эзли. Йөз кешегә йөз гаепләү ярлыгы тага да, фәрештә сыйфатлары белән бизәп, үзен сөттән ак, судан пакь ясый. Моңарчы Нурихан да кешедән күрде. Түгәрәк бәхетенең кырыен кемдер кимереп алган төсле иде. Кем? Менә син шуңа җавап тап хәзер!

Ир, малайның юрганын рәтләп, утны сүндереп килде. Пәрдәләрне кырыйга шудырды. Салкын йолдыз нурында җемелдәгән кар яктысы диварларга буй-буй ак эз сызды. Сәер, бу төн тыныч уза. Кичә генә авылга көтүе белән бүре төшкән иде. Эт җенесе оясында гына ырылдады. Терәүле капкалар, тишек-тошыгы чүпрәк белән томаланган сәләмә абзар-куралар ерткыч өчен киртә түгел. Егерме хуҗалыкка калган Наратлыкта мал-туарның исеме дә онытылган, карт-коры кәҗә дә асрамый. Ә бүре азык сорый. Аларны бу якларга тамак нужасы куып китерде. Көнбатышта урманнар тунала, биләмәләр кечерәя, элеккеге урыс авылларының нигезендә җил уйный. Ачлыкка киселгән бүре нишләсен, кешеләргә ташлана. Үткәннәр яңадан кабатлана, ахрысы. Чү, бүреләр өлеше генә кабатлана. Чөнки аучы Миннеханны кабереннән кузгатып терелтерлек кодрәт иясе җирдә юк. Иртә күзен йомды ата. Аның гомерен рәнҗеш кыскартты микәнни? Яшь чагында «рәнҗү» дигән сүздән, «әбиләр әкияте» дип, Нурихан кычкырып көлә иде. Яшьлектә бөтен нәрсәне дә көлкегә борасың шул. Бүген исә икенче төрле уйландыра. Бер канаты белән Нуриханга да орынды бит ул рәнҗү! Тикмәгә генә чит җирләрдә каңгырамады ир, тикмәгә генә җылы кочаклардан мәхрүм булмады. Тик менә кем күбрәк Солтанбәкләр нәселен каргады икән? Тере килеш тиресе туналган бүреләрме? Әллә...

Нурихан колагын сагайтты. Кемдер шатыр-шотыр өйалды ишеген тырный иде. Исереп кайткан Сафринә, өендә баласын күрмәгәч, монда чапты микән? Бу сиңа бүре генә түгел, атам да котылам димә. «Малайны урлады», – дип, бөтен авылны җыячак. Ә тавыш Нурихан өчен соңгы нокта: шул минутта ук ул Шәрифәне югалтачак. Йоклаган сабыйны кулына тоттырып җибәрергә мәллә? Аннан сыналган саклану чарасына күчәсең: «Бала минеке түгел».

Ир улының өстенә иелде. Мирзабәкнең бәрхет сулышы кытыршы яңакны иркәләде. Юк, малай аныкы! Сулышына хәтле якын хәтта!

«Буып үтерәм мин сине, хәшәрәт хатын, – диде ул, иңенә тунын ташлап. – Баланы имгәтүең генә җитмәгән, Нуриханның да тормышын чатнатасың».

Ул бар куәтенә тышкы ишекне эткән иде, эт, чинап, карга тәгәрәде.

– Фу, хайван, син икән, – диде Нурихан. – Ни пычагыма ишектә тырнагыңны үткенлисең, ә? Мирзабәк минеке, бар, өеңә элдер!

Эт түше белән аңа табан шуышты да өч тапкыр ләң-ләң өрде.

– Әһә, аңладым, хайван. – Хуҗа урман буенда селкенгән кара тапларны шәйләп өлгергән иде инде. – Бу юлысы болар санаусыз. Син миннән ярдәм сорыйсыңмы? Көчле дисеңме Нуриханны? Җүләр мылтык шартлатыр анысы. Тик миңа атарга ярамый, туган. Җә, курыксаң, өйалдына кереп ят. Безнең йортка борын тыкмый алар. Солтанбәк нәселе белән бәрелешсәң, эш харап икәнен чамалыйлар. Бүре хәтере буыннан буынга күчә.

Нурихан, ишек ачылмасын өчен, келәсен шудырды. Дөньяның пеләш маңгаена төкереп, җылы өйдә малай йоклый. Иртәгәсе хәлләр турында уйламаска тырышып, ир дә баш төртте. Ә мендәр һаман таш, уйлар һаман бәйләнчек иде.

-2-

...1970 елда дүрт яктан да урман белән уратылган Наратлыкка бүре ияләште. Авыл тыкрык саен туктап ял итәрлек дәрәҗәдә әкәмәт зур иде. Халыкны урман туендырды. Күрше базарларда кемнәр чиләк-чиләк гөлҗимеш, балан, шомырт, җиләк, капчык-капчык чикләвек сата – Наратлык хатыннары. Капка төбе саен кемдә сап-сары сатлык бура – Наратлык ирләрендә. Иң оста үләнчеләр кайда – тагын Наратлыкта. Шушы гөрләп барган тормышны каяндыр пәйда булган явыз бүре өере пыран-заран китерде. Башта күмәк хуҗалыкның мең баш сарыгын бугазлады алар. Ә беркөнне күзе-башы акайган көтүче Нуретдин авылга кайтып егылды. Аны коедан тарткан салкын су сибеп кенә айныттылар.

– Кырдылар, барысын да кырдылар! Сыңар сыер да калмады. Мин нишләтим, чыбыркы атмый бит, җәмәгать! – дип үкерде ул.

Наратлыкта йорт саен өчәр баш сыер иде. Халык зар елады. Ирләр, балта-сәнәк белән коралланып, өч көн урманны тарады. Әммә бүре өере җир йоткандай юкка чыккан иде.

Ул көннәрдә аучы Миннехан туктаусыз тәмәке төтәтте. Аның мылтыгы ничә ел келәттә тузан йотып, тутыгып ята иде. Борын тишегеннән бөркелгән әче төтен аучының йөзенә сара, гүя Миннехан үзе дә утсыз-ялкынсыз гына пыскып яна иде. Атаның авылдагы мәхшәргә пошынмавы ундүрт яшьлек үсмергә һич кенә дә аңлашылмый иде. Җиңсә, Миннехан аучы гына ерткычларны җиңәчәк, чөнки ул гына бүре аулауның хикмәтләрен белә, аннан күрмәк Нурихан да ау серләренә төшенеп килә иде. Бүре оясына тыгылып, йомры йомгакларны капчыкка тутыру нинди кызык шөгыль иде! Ә ана бүрене эзәрлекли-эзәрлекли көн-төн чапкач, бичараның тәмам йончып авуы, һәм әтисенең аны яланкул тотуы малайның әле дә күз алдыннан китми.

– Әти, кешеләр бүреләрне тапмый икән. Тегеләр искәртмәстән һөҗүм итә дә урман авызында ук эри икән, – диде үсмер төтенләгән атасына.

– Һе, бүре – хәйләкәр зат, улым.

– Син аларны качырмас идең, иеме, әти?

– Мин бүредән хәйләкәррәк бит, улым.

– Алайса, ник юл күрсәтмисең, әти? Абзыйларга булышсаң, рәхмәт яудырырлар иде.

– Хәтерлисеңме, шул абзыйларың өченче ел атаңны бүредән дә яман өзгәләде. Урман каравылчысы Билалетдин җыенда: «Миннеханны авылдан куарга кирәк», – дигән фәрман укыды. Без, имеш, нәселебез белән кан койдык, без – җәллад, Наратлыкта, имеш, безгә урын юк! Ник берсе шунда мине якласын! Кууын кумадылар, вәләкин өч ел капкабызга кеше орынмады, бездән йөз чөерделәр. Моңа күңел бә-әк әрни, улым. Юкса бүрегә ирек бирергә ярамый, ул чүп үлән төсле әрсез, ара-тирә йолкымасаң, урман-кырларны баса. «Син бүреләрнең тамырын корытасың», – диде Билалетдин. Корытмыйм, иту, бүресез урман – күлмәксез катын ул. Әрсез тамырның көчен какшатам мин. Әле дә ерткычларның өер башын гына чүпләдем. Башсыз өер авыл ягына карап иснәнми дә, улым.

– Әти, урманда бөрлегән кызарган, ди. Кыз-кыркын барырга шүрли. Бүре мыжлаган, диләр.

– Быел Наратлык хатыннары базарда күкрәк киереп саталмый икән, – диде төтенләгән ата.

– Әти! Эләктер инде шул өер башын! Кызлар... кызлар сиңа әйтергә кушты, әти! – дип өзгәләнде үсмер.

«Кызлар», билгеле, күплек санда, бергә калдырсаң, ул Озын толым иде. Авылда иң җитез җиләкче Шәрифә иде бит. Дөрес, Озын толым Нуриханга зар түкми, коңгырт күзеннән нур сирпеп, елмаеп кына карап ала. Икәү төнге күктән йолдыз санаганда да, урманчы кызы сызлануларын яшерә. Кем-кем, ә Шәрифә урмансыз кибә-сула. Кырыс Билалетдин абзый кызын нигәдер үзе белән йөртми. Аның күрше авылда сөяркәсе бар, имеш. Ярты гомере аның йортында уза, имеш.

Җиләк-бөрлегәннән тыш Шәрифә дару үләннәре белән мавыга, кыш-яз тирә-яклардан, сырхавына дәва эзләп, кыз янына авырулар агыла, Билалетдиннарның капка төбеннән ук бөтнек, мәтрүшкә, юкә чәчәге исе аңкып тора иде. Шәрифәгә урмансыз яшәү, ә үсмер егеткә аның керфек каккан саен моң түгелгән сагышлы күзләрен күрү авыр, бик авыр иде.

Ата тәмәке төпчеген кытыршы учына басып сүндерде.

– Бүре синең хәсрәт түгел, улым. Тамагың тук, өстең бөтен, кеше кайгысы кайгыртма.

– Әти, бир мылтыкны, мин үзем өерне туздырам, – диде Нурихан.

Аучы Миннехан, зәһәр карашы белән аны яндырып-көйдереп:

– Әтәчләнмә, малай! Син бүре хәйләсен үрәнмәдең әле! – диде.

– Соң... соң үзең бар әлсә. Рас мактаулы бүрече икән син, – дип чәпчеде үсмер.

– Ник мин үземне мыскыллаган халыкка хезмәт итим ди, малай актыгы! Җыенда бугаз ярдылар ничек, җә! Миннехан аталарын үтергәнмени!

– Син... син... әти, бүреләрнең тиресен туный идең.

– Һи, башсыз! – Миннехан черт итеп җиргә төкерде. – Башсыз малай. Акча бит ул. Сезнең тамакны туйдырырлык акча! Мин бит базарда җиләк сатарга катын-кыз түгел. Солтанбәк ирләре, алдырса, эредән алдыра, колагыңа киртлә моны, малай актыгы!

Ә бер кичне аучы озак-озак мылтыгын чистартты.

– Атмаса да көйле торсын, – диде.

Әммә ата исәптә-уйда иде. Бүреләр көннән-көн оятсызлана: авылдагы этләр сафы да сирәгәя. Шул төндә әтисе өйдә йокламады. Нурихан печәнлекне тикшерде – ата анда да юк иде. Үсмер келәткә йөгерде – мылтык элгән зур кадак та буш иде... «Бүре эзләргә киткән», – диде Нурихан. Күзенә яшь тыгылды. Малай өер башлыгы белән көрәшергә әзер, атаның ым кагуын гына көтә иде. Алмады, алмады. Нурихан Озын толым каршында ике сүәм үсәчәк иде ләбаса! Батыр егетләрне кызлар «кит» дип кумый. Әнә Шәрифә, аны малайсытып, «аяк астында чуалма» итенә.

Дәвамы бар >

Рифат СӘЛАХ

И ШИГЫРЬ!

Йөрәккә кара тап кунганмы,
Язылмый нигәдер бер сүз дә.
Йөз тапкыр үзгәреп, яңадан
Үземә кайтамын, үземә!

Язылмас сүзләрне илерел
Язмавың мең тапкыр хәерле.
Моңсызлык сусызлык шикелле
Яндырып киптерә бәгырьне.

Йөз тапкыр үзгәреп карадым,
Яңалык эзләдем үземнән.
Серләрен аңларга соң инде,
Мин узган гасырдан өзелгән.

Үземә кайтырга кирәктер,
Бу яңа гасырда озакладым.
Йөрәктә кара тап түгел ул –
Мин аны сиңа дип сакладым,

И шигырь!..

БҮГЕН ГЕНӘ

Мин дөньяга бүген генә тудым,
Моңа кадәр гүя булмадым.
Алсу таңның йомшак чыгы сыман
Тәгәрәде шигырь юлларым.

Мин дөньяга бүген генә тудым,
Кичә генә җансыз идем мин.
Бүген генә йолдызларга янды
Кап-караңгы тонык күгемнең.

Мин дөньяга бүген генә тудым,
Кичә генә җирдә төн иде.
Бүген иртән йомшак таң чыклары
Күз нурларым булып түгелде.

Мин дөньяга бүген генә тудым,
Моңа кадәр әллә булмадым.
Сезнең өчен җырлар яза-яза
Тәгәрәде гомер йомгагым.

Мин дөньяга бүген генә тудым
Һәм атылдым җиргә ук сыман.
Моңа кадәр гүя яшәлмәгән
Шигъри мизгелләрне юксынам.

КЫЗЛАРЫМ

Сөмбел, Өммегөлсем, Зәлифәгә

Сез үсәсез
Гүзәл чәчкә булып,
Сиздермичә гомер узганын.
Бу дөньяның назлы гөлләре сез,
Якты нурлары сез, кызларым.

Сезне кулга алсам, дөнья тына,
Әверелә җәйгә кышларым.
Өч чәчкәдән җыйган гүзәл бәйләм –
Бөтен яме җирнең, кызларым.

Салкын җилләр
Кагылмасын ялгыш,
Кояш бөркеп торсын нурларын.
Күңелегез тулы сафлык булсын,
Кояш кебек нурлы кызларым,

Сез – гөлләре,
Сөмбелләре җирнең,
Алтын йолдызлары – сез аның.
Күңеләмә яшәү көче иңә,
Сезне күрү белән, кызларым.

Алга илтсен
Барыр юлларыгыз,
Һәрберегез тапсын үз таңын.
Офыклардан офыкларга кадәр
Гел балкыгыз әле, кызларым.

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 «Ватаным Татарстан»ның «ВКонтакте» төркемендә язылырга һәм мини-трактор уйнату турындагы хәбәргә репост ясарга. Яки «ВТ»ның «Инстаграм» сәхифәсенә язылырга, бәйге турында «Актуаль»дәге соңгы постны скриншот ясап, «ВТ»ның аккаунтын билгеләп, үзеңә урнаштырырга.

3 Язылу квитанциясен һәм «Инстаграм» яки «ВКонтакте» аккаунтыгызның сылтамасын безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** **vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 **атнага бер, җомга килә** – **465 сум**

П2409 **Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә** – **1000,92 сум**

Реклама 16+



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Гариф Ахунов романы

... Шакиров

Җигәргә өйрәтелмәгән ат

... Карнай (башкорт язучысы)

Язучы ... Имамов

Татарстан вертолеты

Актриса ... Рязанова

Кычытмаган җирне ...

Кыршылу, ышкылу

Тиешенчә, кирәгенчә

Мультфильмдагы ак аю

Фукс, Либкнехт

... Хари

Ыргыту, ташлау

Пальма төре

Сөенү, шатлану

Борынгы грекларда халык җыелышы

Судноның хәрәкәт тизлеген үлчәү берәмлеге

Хайван борыны

«Роллс-...»

Җырчы Идрис ...

Ким Ир ...

...-лейтенант

Ике кишәрлек арасындагы чик

Сорау алмашлыгы

Кавказда таралган борынгы көмеш тәңкә

Төзелеш, җитештерү биналары комплексы

Козырекы баш киеме

Ихтимал, күрәсең, бугай

...-при

Йомшак, көпшәк агач

Рәис Габдулла

12 ноябрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Сиваш, кое, рондо, дог, бүкән, Лазо, ярак, шифон, хөр, галош, күз, Хәнәви, така, түрә, Закиров, Тунис, япа, амт. **Вертикаль буенча:** башак, Золя, Ухта, кяф, Акита, Сәрвәров, яки, нан, арена, Ван, гәп, им, хан, твист, Шкода, өләшү, Озеров, Серго, шивә.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч вариантын берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 **Казан – Идел елгасының ... ярында урнашкан шәһәр.**
А) сул як;
Б) уртасында;
В) уң як.

2 **Казан университетының иң танылган студентлары кемнәр?**
А) Госман Токымбәтев, Садри Максуди;
Б) Сәгыйть Рәмиев, Габдулла Тукай;
В) Лев Толстой, Владимир Ленин.

3 **«Бозлык чоры» дип нинди чорны атыйлар?**
А) Җир тарихында бу дәвердә ел буе зур территорияләр боз белән капланган һәм салкын булган;
Б) 1917 елгы инкыйлаб;
В) Хрущев идарә иткән еллар.

4 **«Эш» газетасы ничәнче елларда нәшер ителгән?**
А) 1960–2000;
Б) 1918–1920;
В) 1812.

Җаваплар: 1) А; 2) В; 3) А; 4) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17211 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 368

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73,
222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+